# Идел

ИДЕЛ

12/1996


ЯШЬЛӘР ЖУРНАЛЫ

Татар һәм урыс телләрендә чыга

ISSN 0235-974X



Сөй гомереңне, сөй халкыңны,
сөй халкыңның дөньясын!



Татарстан махсус фәнни-реставрация идарәсе



ТАТАР
ЯШЬЛӘРЕ
ЖУРНАЛЫ

1989 елның июленнән бирле
татар һәм урыс телләрендә чы

**Баш мөхәррир**
*ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙ*

**Идарә**
*Дамир ИСХАКОВ*
*Ислам ӘХМӘТҖАНОВ*
*Ләис ХАРРАСОВ,*
бүлек мөхәррире

*Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА,*
бүлек мөхәррире

*Ринат МӨХӘММӘДИЕВ*

*Роза КОЖЕВНИКОВА,*
баш мөхәррир урынбасары

*Рәфикъ ЮНЫС,*
баш мөхәррирнең беренче урынбаса

*Фәридә ХӘСЪЯНОВА,*
баш рәссам

**Мөхәррирләр**
*Гөлсирә ГАЙНАНОВА*
*Марат ЗАКИР*
*Наталья ГРАХАНЦЕВА*
*Ркаил ЗӘЙДУЛЛА*
*Роза ШӘРӘФИЕВА,*
җаваплы сәркәтип
*Сергей МАЛЫШЕВ*
*Фәрид ХӘКИМҖАН*

**Гамәли хезмәткәрләр**
*Альберт СӨЛӘЙМАНОВ*
*Галия ГАЛИЕВА*
*Гәүһәрия КӘРИМУЛЛИНА*
*Миләүшә ГАБДЕЛГАНИЕВА*
*Мөнирә КУЗИЕВА*
*Нәгыйм ШАҺИ*
*Рушания ХАРИСОВА*
*Светлана ЛАТЫПОВА*

*Журнал редакциянең компьютер төркем тарафыннан җыелды һәм битләргә салынды.*

*Журналны гамәлгә куйды: Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, Татарстан язучылар берлеге һәм редакциянең журналистлар коллективы.*

*«Идел»дәге язма, фото яки рәсемнәрне тулысынча йә өлешчә күчереп басу редакциян рөхсәте белән генә башкарыла.*

Журнал Татарстан республикасының Мәгълүм һәм матбугат министрлыгында 222 сан белән теркәлгән.
Журналга Татарстанның.көндәлек басмалар каталогы һәм Рәсәй үзәк каталогы буенча язы була.

*Индекслар: татарчасыныкы — 73951, урысчасыныкы — 73952.*

Редакциянең адресы:
420012, Казан, Мөштәри ур.,14. «Иде
Белешмәләр телефоны: 36-97-32.

© «Идел», 1996, №12

ISSN 0235-974X

12/96 Идел

2


ШИГЪРИЯТ
ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙ
БАРЫСЫ НИБАРЫСЫ



Көяз яңгырашлы, уйлы-гамьле бу иҗатны һич тә «барысы нибарысы» дип булмый. Моңарчы тәнкыйтьче буларак танылган әдип шигърияттә яңа яклары белән ачыла.

5

ТАРИХИ ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫ
РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА
ХАН ҺӘМ ШАГЫЙРЬ



Алтын Урда ханы Бирдебәк белән шагыйрь Әхмәд Болгари төс-кыяфәт белән бер-берсенә охшаган була. Беркөнне алар сүз берләшеп исемнәрен алмаштыралар. Шагыйрь тәхеткә утыра, хан шагыйрь булып сарайдан чыга. Әмма ерак китә алмый...

20, 42

МИЛЛИЯТ
АЛАР ИГЕЗӘКЛӘР ТҮГЕЛ,
ЛӘКИН БЕР КӨННЕ
ТУГАННАР



Бу рәсемдә аларга 19. Тагын ике елдан Разил Вәлиев белән Зөлфәт, «Идел» журналы ачылсын!» дип, театрда листовка бураны уйнатачаклар («Идел», 1994, N 7). Бүген «Идел»гә — 7,5 яшь, ә егетләргә — илле...

50

НӘСЕР
АЙДАР СӘХИБЗАДӘ
ДУАДАК КАЗ

Ялгызлык. Яшь чагында хатын-кызның, өлкәнрәк яшьтә исә парсыз калган ир-атның бәгыренә тия торган сүз бу. Хатын-кызны аралашучанлыгы, һәртөрле мавыгулары, йорт эшләре ялгызлыктан аралап торырга мөмкин әле. Ә буйдак ирләрнең исә хәле мөшкел, һай, бик мөшкел...

58

ША-ЯРЫШ
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
РОБАГЫЙЛАР



«...робагыйларны укый-укый «Идел» егет-кызларын ялыктыра торгач, булмаса, басып чыгарыйк инде, диделәр. Каршы килмәдем. Ләкин аларның сыйфаты мәсьәләсендә җаваплылыкны үз өстемнән төшерәм. Бастырмасыннар, мин ни язмам...»

Басарга кул куелды 10.12.96. Заказ Е-536. Гомум тираж 5000.
Кәгазь форматы 84х108, 1/16. Күләме 8,87 шартлы басма табак. 13,51 нәшер-хисап табак.
Татарстан гәзит-журналлар нәшрияты басмаханәсе.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

# Фәиз ЗӨЛКАРНӘЙ



# Барысы нибарысы

## КИЛЕШӘ!

Нәрсә ул Шигърият? Хисләрнең сурәтеме? Уйларның ажаганымы? Кайгы-шатлыкларның, сөенү-сагышларның күңелдәге кардиограммасымы?.. Кем белә... Әлегә «Нәрсә ул Шигърият?» дигән сорауга бирәүнең дә төгәл җавап бирә алганы юк. Гомумән, аксиомадай җавап була да алмыйдыр, һәм аның, бәлки, кирәге дә юктыр. Әмма... Шигърият никадәр генә Сер булмасын, аның тәгаен бер сыйфат-атрибуты бар, ул — тәэсир итү көче.

Фәиз Зөлкарнәйнең шигырьләрен укыганда әнә шундый уйлар килде. Мин үзем Фәизне шагыйрь буларак җентекле беләм дип әйтә алмыйм. Ул безнең әдәбиятта иң әүвәл үҗәт-туры сүзле, аналитик фикерләүгә ия талантлы тәнкыйтьче буларак билгеле. (Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: бездә хәзер җитди һәм объектив тәнкыйть юк диярлек хәлгә төште. Ул — кайбер газеталарда күзәтү, шәхси шәрехләү рәвешендә яшәп-пыскып килсә, күпчелек матбагада прагматик нигездә теге йә бу «шәхес»кә хезмәт күрсәтү рәвешендә генә хөкем сөрә.) Әдәбият сөючеләрне уйландырырлык җитди китаплары бар Фәизнең («Кешем, асылың кем? 1984; «Әверелеш: шигырь парадокслары», 1988; «Чакма чакмый ут чыкмый», 1991). Соңгы араларда менә көндәлек матбугатта шигырьләре күренә башлады. «Үзе шаян шәкерт, үзе хәким казый да» дигәндәй, ул кушйөрәкле әдип булып чыга инде: үзе тәнкыйтьче, үзе шагыйрь.

Ф.Зөлкарнәй — минемчә, шигырьдә «саф сәнгать» вәкиле һәм күпмедер дәрәҗәдә сюрреалистик адымнар белән эш итүче әдип. Дөрес, иҗатчыга нинди дер тарафдарлык ярлыгы тагу четерекле нәрсә. Әйтик, моннан биш йөз еллар элек Нидерланд рәссамы Босх ясаган рәсемнәрне күргәч, испанлы С.Дали да, бүгенге татар рәссамы Э.Шаһиевлар да бер дә юк җирдән башламаганнар икән, дип куясың. Ә кем ул Босх? Реалистмы? Сюрреалистмы? Авангардистмы?.. Шуңа күрә, Зөлкарнәй шигырьләрен дә һәркем үзенчә аңлар, үзенчә бәяләр. Күпчелек шигырьләрдә күнегелгән ритм гына түгел, хәтта тыныш билгеләре дә юк. Шунсын да искәртик: шәкли оригинальлек кемнәргәдер ошамас. Ә бит төбенә төшеп уйлап карасак, ошау-ошамау — критерий түгел. Мода сеанслары күрсәткәндә дә безгә кайбер модельләр ошап җитми бит. Әйдә, ошатма, үзеңә ошаганын сайла. Булдыра алсаң... Беркем мәҗбүр итми. Сәнгатьтә, бу очракта шигърияттә дә хәл шулайдыр ул.

Моннан унбиш еллар элек миңа Испаниянең Барселона шәһәренең Пикассо музеенда булырга туры килгән иде. Анда, нигездә, Пикассоның үсмер-егет чагында ясаган рәсемнәре куелган. Ул рәсемнәр шулкадәр оста эшләнгән ки, Шишкиннарың бер якта торсын... Хәтерем ялгышмаса, шул реалистик эшләре өчен рәссам 19 яшьтә Сәнгать Академиясенең алтын медален дә алган. Ә аннан соң маэстро иҗаты нинди генә үзгәреш-әверелешләр кичермәгән! Кемнәр тарафыннандыр «абстракт кыланчыклык» дип бәяләнгән күпме эшләр иҗат итмәгән! «Акбүз атка көмешләнгән кара йөгән килешә...» дип башланган дүртюллыгымны, соңгы ике юлын үзгәртеп һәм бу җәһәттән дәвам итеп, «Дөнья тоткан талантларга нишләсә дә килешә!» дип әйтәсе килә.

Ф.Зөлкарнәй — әдәбиятта үз сүзен, үз йөзен тапкан, әдәби процесска философларча киң карашы булган төпле фикерле әдип. Ул — кемнәрдер сыман, үзе йөзә дә белми торып, бүтәннәрне диңгезләрне киңләргә әйдәүче тренер түгел инде. Әдәбиятны Фәиз тыштан да (тәнкыйтьче галим буларак һәм бүгенге әдәби хәрәкәтне оештыручыларның берсе буларак), эчтән дә (төрле жанрларда үзе иҗат итеп) бик яхшы белә. Аның үҗәт ныклыгы исә — үз иманына, үз кредосына тугры булырга омтылу ул.

Равил Фәйзуллин
17 ноябрь 1996.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

# ХАН ҺӘМ ШАГЫЙРЬ



1

Зур ишек үзеннән-үзе акрын гына ачылып китте. Сарай эченә бераз карлыкканрак тавыш яңгырады:

— Бисмиллаһи, сәййидүнә вә мәүләнә, казыйүл-коззай вәл-хөккем, мобәйинүл-фәтава вәл-әхкем, бисмиллаһи![1] Бәдретдин әс-Суари!

Бусагадан бер аягын авыр гына өстерәп Сарай шәһәренең казые килеп керде. Ул вәкарь белән атларга тырыша, әмма бу вәкарьлек кызганыч елмаю гына тудыра иде: казый инде бик карт, аркасы бөкрәйгән, җыерчык баскан йөзе бөрешкән алманы хәтерләтә. «Ничә яшь икән инде моңа? — дип уйлады Бирдебәк. — Үзбәк бабай вакытында ук казый иде бит инде ул».

Казый ханга баш иде, хозурына килеп йөгенмәкче иде дә, тик чак артына авып китмәде. Аннары якындагы тәбәнәк тәңгәлгә килеп утырды, дога кылырга дип ике кулын йөзе алдына җәйде. Бирдебәк тиз генә битен сыпырды да, усал елмайды:

— Җитәр, аксак! Соңгы вакытта бик тәкъва булып киттең әле. Әллә теге дөнья чабудан тартамы?

Казый яңа ханның дорфалыгына күнегеп килә иде инде, бер сүз дә эндәшмәде. Ләкин чал сакал-мыегы астына яшеренгән иреннәренең мимелдәп куюыннан гына аның шактый ук рәнҗегәнен сизәргә була иде.

Ата-бабасына охшамаган әллә нинди оглан булды ла бу! Сарайдагылар Бирдебәк ханнан куркалар һәм инде куралмый башлаганнар иде. Әтисе Җанибәкнең үлемендә дә аның кулы уйнаган дигән ым-шым Сарайда таралырга өлгергән иде инде.

Әлбәттә, ханнан һәркем бераз шөлли, әмма дә ул шөлләү ярату, соклану кебек ефәк бау белән уралган булырга тиеш ләбаса.

Казыйның янәшә торуыннан Бирдебәкнең эче поша башлады.

— Йә? — диде ул түземсезләнеп.

— Тәкъсир! — Казый тагын башын иде. — Калада бер гыйдай шагыйрь пәйда булган.

— Бу яңалыкмы? — дип кычкырып җибәрде хан. — Ул дәрвишләр, суфилар, шагыйрь-шогырлар бөтен каланы басып алды инде. Кая төкермә, берәр шагыйрьгә эләгә. Әрәмтамаклар!

Казый астыртын гына елмаеп куйды. Бирдебәкнең

---

[1] Алла исеме белән, безнең хуҗабыз һәм әфәндебез, казыйларның һәм хакимнәрнең казые, дини кануннарны һәм хөкемнәрне аңлатып бирүче Алла исеме белән!

яшьлегендә шигырь язып маташуын, Ширванда калгай булганда шагыйрьләр диванын җыярга яратуын ул белә иде. Шагыйрьләрнең бергә җыелганда ханның көпшәк бәетләрен бер-берсенә кабатлап, тыела алмый көлүен дә ишеткәне бар иде. Әллә шуны сизеп алган, Бирдебәк тәхеткә менгәч, шагыйрьләрне тәмам куралмый башлады. Үзең белән алмаган кыяга нәфрәт белән карау кеше өчен табигый бит ул.

— Аларның төрлесе бар, — диде казый авыр сулап. — Ә бу — Әхмәд Болгари — базарда төрле сүзләр сөйләп халыкны болгата. Ил белән ничек идарә итү кирәклеген сөйли.

Бирдебәкнең ирен читләрендә ак күбекләр күренде.

— Салкын ташка![2] — дип ысылдады ул.

— Сак астына алдык без аны. Тагын бер сәбәп бар, шуңа гына синең хозурга кердем, тәкъсир.

— Ни?

— Ул нәкъ сиңа охшаган. Суйган да каплаган инде менә.

Ханның тәхет култыксасында яткан бармаклары гасабиланып биеп алды. Бермәл тын торгач, ул кычкырып көлеп җибәрде.

— Ханга беркем дә охшый алмый!

Бәдретдин казый фарсы кызлары тукыган затлы келәмнең бизәкләреннән күзен алмый гына әйтеп куйды:

— Әлбәттә, күктә — Алла, җирдә — хан. Алланың кодрәте зур, ниндидер йолкышка да хан кыяфәте бирә ала. Мин аны зинданда будырып үтерә алам, мәйданда башын өздерә алам, әмма... Синең ихтыярдан башка моңа җөрьәт итә алмадым. Бигрәкләр дә охшаган, игезәкләр кебек.

Бирдебәк үзалдына беравык уйланып торды. Кеше кешегә ничек ике тамчы су кебек охшый ала? Ходай шулай нигә дә булса ишарә итәме? Әллә бабайларның каны караларда уянып, аларны шулай кызык итәме? Чыңгыз балаларының орлыгын гасыр җилләре бер диңгездән алып икенчесенә кадәр чәчеп ташлады бит... Юкса Бирдебәккә бер кул селтәү җитә, ул бичара шагыйрьнең башы дүңгәләк кебек тәгәрәп китәчәк. Хәер, анысына өлгерер.

— Бире китерегез, багыйм, — диде ул әмер көтеп утырган казыйга.

Бәдретдин авыр кузгалып титаклый-титаклый ишеккә таба китте. Аның артыннан зур ишек үзеннән-үзе авыр гына ябылды.

Хан тәхетеннән торып арлы-бирле йөри башлады. Тәне язылгандай булды, миен чорнаган пәрәвез коелып төште. Ул үзенә охшаган шагыйрь турында оныткан иде инде. Дөнья уйлары тәмам биләгән иде аны — үзе дә сизмәстән дивар кырына куелган көрси янына килеп басты. Көрсидә асылташлар белән мөлдерәмә тулы алтын савыт тора иде. Хан янә Ширванны хәтерләп куйды, атасының авырып түшәккә егылуын ишеткәч, ул үзенә тәгаенләнгән биләмәсен ташлап Сарайга кайткан иде. Үзе юкның күзе юк, мондагы биләргә ышаныч аз, Җанибәк үлгә, үзләренә кулай ханзадәне тәхеткә күтәреп куюлары да бар иде. Ширван шулай итеп кулдан ычкынды. Тәхеттә ныгып алуга Бирдебәк олысларга атчабарлар җибәрде, гаскәр җыярга боерды. Олыс әмирләре ханның ниятен хупладылар, Иранда аларны алтын-көмеш, затлы келәмнәр, коллар, сылу кызлар көтә иде. Тик менә Болгардан гына хәбәр юк. Бер чирүне шунда җибәреп, тәкәббер әмирнең тузанын коясы булыр, ахрысы. Тиздән, тиздән ханның иксез-чиксез гаскәре, әллә ничә чакрымнарга сузылып, елан кебек боргалана-сыргалана, Каф тавы артына шуышыр. Аның юлына аркылы төшеп кара! Хан кинәнеп көлеп җибәрде.

Ишектән берәүне эчкә этеп җибәрделәр. Керүче, тигезлеген тота алмыйча, ханның аяк астына ук килеп йөзтүбән егылды.

Күз алдыннан сөңгеләр күтәргән гаскәр югалды, хан янә сарай мәшәкатьләре эчендә калды.

— Тор, — диде ул, йөзтүбән ятучының шәрә башына итек очы белән төртеп.

Кеше авыр гына күтәрелде. «Кыйнаганнар», — дип уйлады хан.

— Әссәләмагаләйкүм!

Хан аның сәламен алмады. Ул шашып калган иде — каршында ул үзе — Бирдебәк басып тора! Шул ук гәүдә, шул ук җирән сакаллы йөз, зәңгәр күзләрендә мыскыллы очкыннар биешә.

Шагыйрь шаркылдап көлеп җибәрде.

— Син миңа охшагансың икән, Бирдебәк!

— Хан үз-үзенә генә охшый ала, бичарам. — Бирдебәк, шагыйрь белән икәүдән-икәү генә каласы килеп, шыгаулларга[3] чыгып торырга ымлады.

— Мәйданнарда халыкны болгатып ниләр сөйләнеп йөрисең... — Хан сүзен «йолкыш» дип тәмамламакчы иде дә, әмма шагыйрьнең уеп алган зәңгәр күз карашын тоеп, теле сөрлегеп китте.

— Мин гаделлек турында сөйлим, — диде шагыйрь.

— Гаделлек... — Бирдебәк көлеп куйды, аннары акрын гына атлап тәхетенә таба китте. — Ни беләсең син гаделлек турында? Еш кына гаделсезлек тә гаделлеккә әверелә.

— Хан гадел хөкем итәргә тиеш, — диде шагыйрь үҗәтләнеп. — Ул салымнарны халык күтәрәлгәнчә салырга, угры түрәләрне җәзаларга, илбасар сугышлар алып бармаска тиеш.

— Менә син гаделлек турында сафсата сатып халыкны болгатасың, ахмак кешеләр гаделлек табабыз дип фетнәгә кузгала. Бераздан минем ясаулларым аларны чебен урынына сыта. Елга кебек кан коелачак. Син шуны аңла, шагыйрь: ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас. Димәк, гаделлек турында сөйләп, син үзеңә ияргәннәргә гаделсезлек эшлисең. Шуңа күрә мин афәт чыкканчы ук синең башны чабарга боерам. Сиңа карата бу гаделсезлек булыр, чөнки син дә адәм баласы, сине дә Алла яраткан, әмма синең сафсатаңа иярәчәк беркатлы бәндәләр өчен бу гаделлек булачак. Мин шулай күбрәк кешенең гомерен саклап калам.

— Хан гадел хөкем иткәндә берниндә дә фетнә кузгалмый.

Бирдебәкне бу әңгәмә туйдыра башлаган иде инде.

— Син Болгардан бит әле? — дип бәхәсне өзде ул. — Узындыгыз сез. Ясакны вакытында түләмисез, әмирегез гаскәр җыярга да ашыкмый.

— Җучи олысы ямаулыклардан тегелгән юрган кебек,

[2] Салкын таш — Сарай шәһәрендә җәза мәйданы

[3] шыгаул — ишек сакчысы

— диде шагыйрь. — Һәр ямаулык үзе ил-көн. Һәр ил-көн үз көнен үзе күрергә тиеш. Нигә әле Болгар халкы әллә кайдагы Каф тавы артында яу чабарга тиеш ди?

Бирдебәкнең йөзе агарып чыкты, җирән сакалы дерелдәп алды.

— Син кайдан ишеттең бу турыда? — Аның тавышы ысылдап чыкты.

— Сүз иясе беләν йөрми, — диде шагыйрь сүрән генә.

Хан тәхетеннән төшеп тагын ары-бире йөри башлады. Аның чиктән тыш ярсыганын күреп, Әхмәд Болгари инде үзенең исән-сау калуыннан өмет өзгән иде. Хәер, Салкын ташка эләккән кешенең кире чыгуы бик сирәк була торган хәл. Яшәүгә өмет итсә, ул хан белән болай ачыктан-ачык сөйләшмәс тә иде, бәлки.

Бирдебәк, сүз тотмый торган әмирләргә, морзаларга ачуы килеп, йөренде дә йөренде.

— Ни калган безгә Иранда? Син башта үз йортыңда тәртип урнаштырырга тиеш.

— Тиеш?! — дип кычкырды ярсыган хан. — Сез шагыйрьләргә акыл сатуы җиңел. Әмирләргә яу кирәк! Аларның байлыгы, малы артсын өчен хан гаскәрне чит илләргә юнәлтергә тиеш. Менә мин ни тиеш! Даладагы морзаларга Сарайдан борын чыгармаган хан кирәк түгел. — Бирдебәк шагыйрьне теге дөнья кешесе саный иде, шуңа күңелдәгесен әйтеп ташлады. — Тәкияда[4], байларның сәдакасын көтеп утырганда акыллы булып кылану җиңел ул. Ә син менә бу тәхеткә утырып түрә итеп кара!

— Әйдә соң, — диде шагыйрь шаярып. — Алмашыйк урыннарны. Без бер-беребезгә охшаганбыз, беркем дә аера алмаячак.

— Кызык... — Бирдебәк тәхетенә килеп утырды, култыксадагы бәллүр йомрыны учы белән каплады. Бер атна, бер атна гына мескен җилән киеп, тәкияның салкын диварына арканы терәп Мәңгелек турында, бу дөньяның фанилыгы турында уйланып утырасы иде бит, чыннан да... Һәр кешедән шикләнеп, сарай эчендәге һәр ымшымга колак салып, тәхет өчен калтырап утырудан туйды ич тәмам. Ләкин, ләкин... түрә тоту искиткеч ләззәт бирә шул. Ир-ат өчен башкаларны буйсындырудан да зур бәхет тагын бармы икән? Күктә — Тәңре, җирдә — хан!

Шулай да бер генә атнага иңгә таш булып баскан түрәлекне коеп төшереп, нигә бер дәрвиш булып алмаска? Һарун әр-Рәшид[5] тә хәерче киеменә киенеп Багдад урамнарында кемсәләрнең ни турында сөйләшеп йөрүен тыңларга яраткан, диләр бит. Бирдебәк хакында нинди гәп сата икән каралар? Ниһаять, хан бер генә атнага дөньялыкта Әхмәд Болгари дигән шагыйрь булып алырга карар кылды. Соңыннан ул тәхетне кире кайтарып алачак бит, бармагында Бату бабайдан тапшырыла килгән хан тамгасы төшерелгән көмеш йөзек. Ул бары тик хан бармагын гына коршаулый ала.

— Бер атна минем тәхеттә утырып кара, — диде ул шагыйрьгә. — Күрербез, ничек сайрарсың икән.

— Борчылма, Бирдебәк, — диде Болгари, — шагыйрь хан була ала, хан шагыйрь була алмый.

— Шагыйрьләрнең бушкуык икәнен мин күптән беләм. — Бирдебәк асылташлар беркетелгән кеш якалы чапанын сала башлады, Һиндстаннан китерелгән зур зөбәрҗәт ташлы чалмасын бер читкә куйды, мышный-мышный болгари сәхтиян читегенә тотынды.

Шагыйрьгә алай чиләнергә туры килмәде, ямалган, җөйләнгән тузанлы иске җиләне, төкәнгән кеше гомере кебек, идәнгә шуып төште. Шул җиләнгә төренеп Бирдебәк ишеккә атлады.

— Онытма, бер атнага, — диде ул, киенеп-ясанып хан тәхетенә менгән шагыйрьгә борылып.

Зур ишек җиңел генә үзеннән-үзе ачылып китте. Бирдебәк чыкты, әзмәвердәй ике шыгаул янә ишек катына басты.

— Аh! — дип кычкырып җибәрде тәхеттәге шагыйрь, үзе гасабиланып бармакларын уды. — Йөзегемне урлаган, йөзе кара! — Ул шыгаулларга кибарәнә кулын селтәде: — Барыгыз, йөзегемне кире кайтарыгыз. Угрының хәзер үк башын чабыгыз!

Шыгауллар бер булып ишеккә ташланды. Теге якта ыгы-зыгы купты, шык итеп нидер таш идәнгә килеп төште.

Бераздан шыгаулның берсе тез белән шуыша-шуыша тәхеткә якынлашты. Учында Батулардан, Бәркәләрдән калган көмеш йөзек дерелди иде.

## 2

Хан килеп кергәндә Ханикә ахирәт кызлары белән энҗе арчып утыра иде. Аны күрүгә кызлар, бүре күргән киекләр кебек, тиз-тиз кайсы-кая таралышып бетте. Ханикә кырында кыйгач кашлы, зур кара күзле, озын толымнары тезенә үк төшкән бер чибәр кыз гына калды. Әхмәд атлас тышлы мендәрләр өстенә барып утырды. Сүз кушарга ашыкмады. Ни әйтергә кирәк, нидән сүзне башларга — ул белми иде. Шуңа күрә доганы да озаклап укыды.

— Кәефең юкмы әллә, солтаным? — дип сорады Ханикә назлы тавыш белән. Ул инде иренә сәерсенеп карый иде.

Әхмәд йөзенә арыган кыяфәт чыгарып:

— Мәшәкатьләр... — диган булды.

Чибәр кыз Ханикә кулындагы сабага кымыз койды. Сабаны ханга сузганда хатынның аккош муенындай ап-ак беләкләре ачылып китте. Әхмәд, сусыз сахрада интеккән мөсафирдай, йотлыгы-йотлыга кымыз эчте. Эче яна, бөтен тәне дерелди иде аның. Ул тагын комсыз карашын хатынның беләкләренә, ефәк күлмәктән тёртеп торган күкрәкләренә күчерде, татыйсы рәхәтлектән оеп аякларын сузып җибәрде. Чибәр кыз каядыр югалды, Ханикә иелеп аның читекләрен салдыра башлады. Ләкин Бирдебәк читекләре аңа кысанрак, һич тә салынырга теләмәделәр. Ханикә мышнап чыкты, маңгаенда тир тамчылары күренде, алар йөздәге иннек-кершәнне ерып аска шуыштылар. Хатын гаҗизләнеп аптыраулы карашын янә Әхмәднең йөзенә күчерде.

Тәкате калмаган хан хатынны кочаклап алды, «соңыннан, соңыннан», — дип пышылдады.

Ханикә дә уһылдап куйды, елан кабыгын салгандай ефәк күлмәк эченнән шуып чыкты...

— Син Бирдебәк түгел! — диде ул, бераз сулу алгач.

— Тилердеңме әллә?

— Ул мондый түгел иде...

— Нинди — мондый?

Хатын күзләрен аңа төбәп беравык тын ятты. Ул әйтергәме-юкмы, дип икеләнә иде, ахрысы.

[4] тәкия — дәрвишләр яши торган бина, орден
[5] Һарун әр-Рәшид — гаделлеге белән дан алган легендар хәлиф

— Шундый... Дәртле...

«Артыграк тырыштым бугай», — дип уйлады Әхмәд. Аның хатын-кыз күрмәгәненә бишбылтыр иде, шуңа ач ерткыч күгәлгә ташланган кебек алны-артны оныткандыр инде.

— Сагындым, — диде ул, бүтән сүз таба алмады.

— Кичә генә миндә булган идең ич әле... — Хатын тагын сынап аңа карады.

— Мин көн дә синең янда булырга риза, бүтән хатыннарны күрәсем дә килми...

Хатын сикереп торды, әрфия япма белән имиләрен каплады.

— Юк! — дип ачыргаланып кычкырды ул. — Син Бирдебәк түгел, син башка кеше!

Әхмәд ут чаккандай сикереп торды да, хатынның иңбашыннан умырып тотты.

— Кычкырма, ахмак! — дип ысылдады ул, — мине хан түгел дисәләр, ят кеше белән йоклаган өчен синең дә башыңны чабачаклар. Чапмасалар да, син инде хан хатыны булмыйсың.

Ханикә түшәккә йөзтүбән ятып сулкылдый-сулкылдый елый башлады. Елап туйгач, торып утырды. Керфекләрендәге сөрмә күз яше белән агып йөзен буяп бетергән иде.

— Кем син? — диде ул калтыранган тавыш белән.

— Бирдебәк, — Әхмәд аның күзенә карап мыскыллы елмайды. — Син мине аңладыңмы?

Ханикә ханның кысылган иреннәрен, зәңгәр пыяла кыйпылчыгы кебек салкын бәбәген, җирән сакалын карашы белән капшап үтте дә, «аңладым», дип пышылдады.

...Иртән аны ишек катында нөгәрләре белән ясаул көтеп тора иде. Ул иярләнгән ап-ак аргамакка җиңел генә менеп атланды да, Алтын ташка[6] юнәлде.

Сарайда салкынча иде. Әхмәд бәллүр савыттан әфлисун алып әрчи башлады. Яртылаш әрчегәч, җимешне янә савытка куйды. Тып-тын иде — шомлы тынлык. Ишек төбендә ике шыгаул сын кебек катып калган. Әхмәднең җанын нидер изеп тора иде. Күңел сизенүнең юкка түгел икәнен ул әйбәт белә. Ни көтә аны тәхеттә? Ямаулы җиләнен бөркәнеп бу шыксыз сарайдан чыгып йөгерәсе килде аның. Анда — урамда, тәкиядә тормыш үз агымына җай гына аккан икән, Ходай бүлеп биргән гомердә, мәңгегә килгән кебек кыланып, үзең кебек ике аяклы кемсәләрне буйсындырырга маташып, ялтыравыкларга, чүпрәк-чапракка алданып, ыгы-зыгы диңгезендә баталкалка матавыклану шулкадәр дә мәгънәсез эш икән лә! Ләкин артка юл юк иде. Тәңре биргән форсаттан файдаланып, гомереңнең соңында нигә хан булып уйнап алмаска? Тормыш дигән бу затсыз уеннан чыкканда, калучылар быргы уйнап, зөрнәләр кычкыртып, барабаннар бәреп калсын. Һәр юлның да ахыры була. Кырыйдагы канауга берәм-берәм юлчылар тәгәрәп кала. Тыштан кайгы кыяфәте чыгарып, эчтән үзләре өчен шатланып юлдашлар алга таба үтә. Тик юкка шатланалар — алар да әллә ни ерак китә алмый.

Ул бит шигырьләрендә ханнарны гадел булырга өйрәтә иде. Менә хәзер үзе хан — гаделлек кылырга бернинди киртә дә юк төсле...

Хан мәчетенең мәзине килүен хәбәр иттеләр. Әхмәднең уйларыннан бүлдергәнгә ачуы килде.

— Йомышы ни? — диде ул канәгатьсез тавыш белән. Иртәнге якта ул гадәттә кеше белән аралашмый, үз эченә йомылырга ярата иде.

Бусагачы аңа гаҗәпләнеп карады да, күзен яшереп:

— Һәрвакыттагыча, тәкъсир... — дип мыгырдады.

Әхмәт үзенең ялгышын аңлап алган иде инде. Шуны төзәтәм дип тагын бер ялгыш ясады:

— Кәефем юк иде...

Ханга зарланырга ярамый! Үз-үзенә ачуы килүдән аның йөзе бүртенеп китте. Дәрвишлектән тиз генә арынып буламыни? Югыйсә ул борынгы бәкләр нәселеннән иде. Бату Олуг каланы яулап алгач, аңа каршы сугышкан өчен, алар нәселен кырып бетерергә кушкан, Әхмәднең тармагы гына ниндидер могҗиза белән исән калган. Биләмәсез биләр мулла-мунтагай булып, дәрвишлеккә китеп көн күрергә дучар ителгән. Әхмәднең Бату балаларына ыру үче дә бар иде.

Ул кискен ишарә ясап, «керсен!» сүзен теш арасыннан сөзеп чыгарды.

Ишектән сирәк сакаллы, кысык күзле, керләнгән чалма кигән мәзин килеп керде, тезе белән шуышып тәхеткә таба килә башлады.

— Тор! — Мәзиннең догага дип күтәрелгән кулы гәүдәсе буйлап камчы кебек салынып төште. Әхмәд мәзиннең кем икәнен аңлаган иде инде. Бирдебәкнең шымчысы! Күрәсең, көн дә иртән ханга ым-шымны җиткерү аның вазифасына керәдер.

— Йә!

— Сарайда яман хәбәрләр йөри, олуг хан... — дип сак кына сүз башлады мәзин.

Әхмәд эндәшмәде, шымчының сүзне дәвам итүен көтте. Тегесе ничек башларга белмичә угалана, үз хәбәреннән үзе үк шүрли иде.

— Сине хан түгел, ә мәкер белән тәхеткә менгән э...э... шагыйрь дип гайбәт тараталар.

— Нинди мәкер?

— Имеш, төс-кыяфәтнең охшашлыгыннан файдаланып, бер йолкыш шагыйрь синең тәхеткә менеп утырган.

Әхмәд ярсып тәхеттән сикереп төште, янәшәдәге алтыннан ясалган агачка ялгыш чабуы тиеп китте, ботакларга җимешләр кебек беркетелгән асылташлар җил искәндәге кебек тибрәнеп алдылар, бер якут өзелеп идәнгә төште, келәм өстендә кан тамчысы кебек алсукызыл төсләр белән уйнап алды.


Дәмәшкъ кылычын суырып алып, Әхмәднең шымчыны чабып үтерәсе килде. Әмма кылый яисә чепи булганы өчен кеше үз күзен үзе чыгарамы? Салпы яисә яфраксыз булганы өчен кеше үз колагын үзе кыеп төшерәме? Ханның һәр җирдә күз-колагы барын һәммә кеше белеп торырга тиеш. Беләләр, әмма гайбәт тараталар, ниндидер ният коралар. Димәк, курыкмыйлар.

— Кемнәр тарата мондый коткыны?

— Туганнарың. Бигрәк тә Танышбәк. Хан үз-үзенә охшамаган, диләр.

Әхмәд шымчыга чыгарга ымлады. Әлбәттә, туганнарның һәммәсе аның тәхетенә кызыга, үзен генә моңа лаеклы дип саный. Аларга аны бәреп төшерергә сылтау гына кирәк. Тәнибәк, Җанибәкнең исәпсез огланнары үзе өчен нинди куркыныч көч икәнен ул аңлый иде. Илйорт иминлеге ханның каты куллы булуында. Курку — менә

[6]Алтын таш — хан сарае урнашкан җир




дәүләтнең нигезе. Ул эт өерен юкка чыгарырга, фетнәне тамырыннан йолкып алырга кирәк. Халык өчен гаделлек шунда гына киләчәк. Кан туганлыгы аның кулын бәйләп тормый.

Почмактагы кетер-кетер тавыш аның уйларын бүлде. Тычкан... Әхмәд чүәген салып шул якка томырды. Ләкин тычкан бераз тынып торды да, тагын кимерүен дәвам итте. Хан сараемы, гидай алачыгымы — тычканга барыбер.

Әхмәд, ныклы карарга килеп, кул чапты.

— Иртәгә барлык ир туганнарымны сарайга чакыр, — диде ул, килеп кергән диван бәгенә. — Мәҗлес җыям, табынны мул әзерләгез!

3

Огланнар килеп җиткәнче ул табын ыруының бие Саруҗаны хозурына чакырды. Бу ыру Чулманның сул ягын били, шуңа Әхмәд бине күреп тә, ишетеп тә белә иде. Кансыз, гайәрь кеше Саруҗа. Кара чутыр йөзле, кысык күзле, кәкре аяклы бу яугир Сарайдагы купшылыкны, кыланчыклыкны яратмый, бик кирәк булганда гына калага килә иде. Ул астан сүз йөртүне, алда елмаеп, арттан бавырга пычак кадауны аңлый алмый, чын ир маңгайга маңгай килеп җиңәргә тиеш дип саный иде. Әмма җиңәргә кирәк булганда, дошманыңның коралыннан да файдаланырга мәҗбүр буласың.

— Тиздән минем ир туганнарым мәҗлескә җыела, — диде Әхмәд. — Син беләсең, аларның һәрберсе юрганны үзенә таба тарта. Ә Җучи олысы бер йодрыкта булырга тиеш. Шул чакта гына без дошманны җиңә алабыз. Ширван белән Арранны яңадан кул астына кайтарыр вакыт җитте. Һулагу огланнары бер-берсе белән орышып дәүләтне харап иттеләр. Үзбәк туруннары да үзара кылыч күтәрсә, олысыбыз өстендәге Чыңгыз туы[7] авып төшәчәк. Ил иминлеге өчен огланнарның Тәңре янына китүе кирәк. Гаделлек шунда! — Ул бер мәлгә туктап калды. Кылыч сабын кыскан бармаклары агарынып китте. Саруҗа келәмнән күзен күтәрмичә ханын тыңлый иде.

— Яу чыгар алдыннан безгә бер йодрыкка тупланырга кирәк, — дип фикерен янә кабатлады ул. — Мин ым кагуга, синең нөгәрләрең огланнарны бабаларыбыз янына җибәрергә тиеш.

— Төшендем, олуг хан...

— Болгар әмиреннән бер хәбәр дә юк. Үз чирүен безгә кушасы килми бугай. Иртәгә үк анда кузгалырсың, мин сине Болгар әмире итеп түрә кылам. Каршылык күрсәтүчене гөрзиең белән сыт!

— Баш өсте, олуг хан.

— Яуга чыккач, уң канат синең кул астында булыр. Әйттем!

[7] ту — байрак

Саружа, арты белән чигенеп, ишеккә таба китте. Әхмәд тәхетенә кырын ятып ирен читләре белән елмайды. Тәңре аңа тәхет биргән икән, тәхетенең югарылыгын ул дөньяга күрсәтә белер. Урда даны, сәүдәгәр кулы тиеп киткән алтын тәңкә кебек, яңадан-яңа төсләр белән илләр-җирләр өстендә җемелдәр.

Ил башын җиңүле яулар гына караш җитмәслек биеклеккә күтәрә. Ул үз исемен кылыч белән тарих сәхифәләренә яза. Бирдебәк исеме белән тарихка кереп калырга язган икән, шулай булсын! Әхмәд дигән шагыйрь үлде, Бирдебәк дигән хан хәзер дөньяны шаулата. Кешеләр кансыз, дәһшәтле хөкемдарларны гына истә тота. Чыңгызлар, Батулар шаны искермәс, ә олыска Ислам нурын иңдергән, кылыч тотмый гына ил-көнне туплап тоткан, тынычлыкны барыннан да өстен куйган Бәркә ханны кем хәтерли?

Огланнарны юк иткәч, нәүбәт ыру әмирләренә җитәр. Һәр ыру үз ягын каерганда, илдә иминлек булмый. Аларны Чыңгыз кебек болгатып, бутап бетерергә кирәк. Җучи олысында бер ыру гына калырга тиеш. Бер илкөн!

Аңа әнисе — мәрхүм Җанибәкнең хатыны Тогай-Туглы килүен хәбәр иттеләр. Ишектән йөзе акшарланган юан карчык килеп керде. Ул вәкарь белән акрын гына атлый, арттан озын күлмәк итәген унлап кәнизәк күтәреп бара. Хан, тәхетеннән төшеп, аны каршыларга китте, кулыннан җитәкләп килеп үзенең уң ягына утыртты. Карчык кара төртмә күзе белән аны тишеп алды да, йөзенә битарафлык чыгарып, авыз эченнән генә ниндидер дога укыды.

Пулатка кунаклар керә башлады. Ул Ханикәне дә аягүрә каршылады, сул ягына утыртты. Һәркем үз урынын белә иде, шауламый гына урнашып, барысы да бергә дога кылдылар. Танышбәк тәхеттән ерак түгел уң якка урнашып, мендәргә кырын ятты. Хан аның мыскыллы елмаюын күз кырые белән күреп калды.

Зур күн капчыкларда елкы ите кертә башладылар, кымыз ташыдылар. Табын җиләк-җимешләр белән тулы иде. Көмеш табаклар өстендә бавырчыларның пычаклары елык-елык уйнады. Анасы аңа кымыз салып бирде. Ул уртлап алгач, саркытын[8] Танышбәккә сузды. Ханның мондый хөрмәтенә гаҗәпләнгән огланның касәне алганда кулы җиңелчә дерелдәп куйды.

Бавырчылар һәр кунак алдына табак белән ит куйдылар. Кымыз бераздан телләрне яздырды — шыбыршыбыр сөйләшү, ара-тирә көлү тавышлары яңгырады.

Пыяла чүлмәкләрдәге шәраб, батып барган көньяк кояшы кебек, моңсу нурларын табын өстенә сирпеде.

Борынгы йола буенча шәраб тулы касәне кулына алган кеше җыру әйтергә тиеш иде. Танышбәк ханга карап җырлады:

Дала-алардай кылганнар шавы,
Кызыл төлке казгышла-ар аулый...

«Ул үзен кызыл төлке итеп сизә бугай, — дип мыскыл белән уйлады Әхмәд. — Саркытны эчү тәмам уяулыгын алган».

Ул кулын күтәреп мәҗлескә тынарга кушты.

— Сарайда минем турында төрле сүзләр йөри икән, — диде ул карлыккан тавыш белән. — Имеш, мин — мин түгел. Янәсе, тәхеттә мин — Бирдебәк утырмыйм, ә миңа охшаган ниндидер йолкыш шагыйрь утыра. Мин бу ялага колак та салмаган булыр идем, әмма туганнарымның минем артта шундый коткы таратуы рәнҗетте.

Табында чебен очкан тавыш та ишетелә иде. Бавырчыларның табаклар өстендә елык-елык килгән пычаклары хәрәкәттә туктап калган, ә Танышбәк, бөгелеп көзән җыера башлаган аягын сузып җибәрергә җөрьәт итмичә, мендәрдә кырын ята иде.

— Йә, кайсыгыз мине Бирдебәк түгел, ди?

Андый кеше табылмады.

— Менә уң ягымда анам утыра. Мин аның бәгыреннән өзелеп төшкән. Кайсы ана үз баласын ятлар белән буташтырыр? — Әхмәд кырындагы корткага борылды. — Анам, әйт бу адашкан огланнарга, әйт минем кем икәнне!

Карчыкның кара төймәдәй эчкә баткан күзләре янә аны тишеп үтте. Бу караштан бернәрсәне дә яшереп булмый иде.

— Син — улым, Бирдебәк, — дип бытылдады карчык.

— Сул ягымда газиз хатыным утыра. Мин аның белән ничә төнне бер юрган астында үткәргән. Кайсы хатын үз ирен ятлар белән бутый ала? — Әхмәд кырындагы хатынга борылды. — Хатыным, әйт бу адашкан огланнарга, әйт минем кем икәнне!

Хатын башын күтәрә төшеп табындагыларга күз йөртеп чыкты. Аннары өзеп-өзеп әйтте:

— Син — ирем... Бирдебәгем...

— Корьән алып керегез! Ант итсеннәр, — дип кычкырды Әхмәд.

Яшел тышына алтын хәрефләр төшкән калын китапны күргәч, Ханикә артка тартылып куйды, үзе дә сизмәстән, кулын яшерде.

Мәрхүм Җанибәкнең хатыны тиз генә кулын Корьән өстеннән шуытып алды, «Ант», — дип бытылдады.

Ханикә дә, ханның күзеннән бөркелгән салкын зәңгәр уттан куырылып, буар елан авызына суырылып килгән куяндай дерелдәп, нәфис бармакларын изге китап өстенә куйды.

Бераздан хатыннар үз өйләренә кайтып киттеләр. «Исән-сау каласы килү, тәхет эргәсендә булашу Алланы да оныттыра, теге дөньяда җавап бирәсе истән чыга, тәмуг газаплары да ерагая...» Чыгып барган хатыннардан чирканып Әхмәд йөзен сытты.

Аяклардагы[9] шәраб огланнарның кан тамырларына күчеп уйный башлады, — алар тәхеттәге ханны да онытып сөйләшәләр, бер-берсе белән бәхәсләшәләр иде.

— Кырымдагы фрәнекләрнең дә арт сабагын укытырга кирәк! — дип кычкырды исереп алган Танышбәк. — Тамга бәясе бигрәк арзан бит.

Кайсыдыр җәелеп киткән огланның кабыргасына төртеп алды. Андый мөһим эшләр турында ханның рөхсәтеннән башка монда сөйләшергә ярамый иде.

«Нинди тәкәбберләр! Чыңгыз нәселеннән булгач, үзләрен Алланың кашка тәкәсе дип хис итәләр. Болар гына дөньяның кендеге. Һәрберсе төшендә дә үзен тәхеттә итеп күрә, шул ялтыравык мескен урындыкка менәр өчен атасын, баласын, карындашын бугазларга әзер. Ябай

[8] саркыт — хан эчкәннән соң касә төбендә калган эчемлек. Хан хөрмәте

[9] аяк — касә, савыт

нәселдән булсаң, башың пулат булса да, болар арасына кысыла алмыйсың», — дип уйлады Әхмәд.

Тиздән Бату йортыннан тәхеткә дәгъва итәрдәй бер кеше дә калмаячак.

Диван бәге кул чабуга, алар каршында мангыт ыруының атаклы җырчысы Әсән пәйда булды. Думбра тавышы көчәя барып, табындагыларның шыбырдашканын басып китте. Җыручы ханга мәдхия укый — аның гаделлегенә, миһербанлылыгына дан җырлый иде.

Матур сүзләр белән Әхмәдне алдап булмый. Ул үзе күптән түгел генә мескен җилән ябынган дәрвиш шагыйрь иде. Шагыйрь алдында сүзнең бер дәрәҗәсе юк. Чын уйларын яшерер өчен ул аларны кызганып тормый. Купшы, көяз чәчәкләр агымсулар өстенә сибелә, аста ләмгә баткан кара таш кымшанып та карамый, аның тирәсендә вак балыклар уйный, әкәм-төкәмнәр рәхәт чигә. Кара таш серен зирәкләр генә күрә. Җете чәчәкләргә кызыгып сузылган кешене агымсулар алып китә, чоңгылларга илтеп ташлый.

Менә бу Әсән дә монда үзен иң акыллы кеше дип саный. Ханнар килә-китә, шагыйрь даны мәңгелек, дип уйлый ул. Шуңа төннәр буе кара сулардан энҗе бөртекләре эзли. Тәхете юкка күрә коры сүздән бәхет таба.

Нигә хәзер Әхмәдкә шигырь язу? Тәхеткә ия кешенең яшәве — иҗат, ул сүзләрне түгел, дөньяны вәзенгә сала.

Ул күп күрде сарай шагыйрьләрен... Алар төнлә олуг әшьялар турында язалар, көндез ханның рәхимле күз карашын аулыйлар.

Нигә һәркемнең көтү күз уңында буласы, ишләренең уйлары белән идарә итәсе килә.

Әхмәд яшьлегендә дөнья малыннан ваз кичеп, вак мәшәкатьләрдән качып дәрвиш булып китте. Ләкин бу да кешеләр күңелендә аерым урын эзләү түгелмени? Җылы сүз көтеп тәкияга килүче булмаса, аның робагыйларын тыңларга башка дәрвишләр җыелмаса ул гасабилана иде бит! Димәк, ул җаны-тәне белән Аллага якынаерга тырышмаган, ә үзе кебек мәхлукларның рухында түрәлек кылырга омтылган.

Дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, ялангач, ачлытуклы яшәве белән ул үзенең башка кешеләрдән аерылып торуын күрсәткән...

Кара суларга батып барган кояшның соңгы нурлары төште. Су өсте аксылланып киткәндәй булды, Әхмәд анда пәйда булган майлы йөзләрне шәйли башлады.

«Бу дөнья киселгән тырнакка тормый, — дип уйлады ул. — Шуңа күрә булган бөтен ләззәтне татырга, булмаганын уйлап табарга кирәк. Ләззәт уйлап табу үзе дә ләззәт бирә ләбаса. Ә моңа тәхетле булганда гына ирешеп була.»

Ул табындагыларны канлы күзләре белән айкап чыкты да, ишек төбендә утырган Саруҗага ым кагып башын иде.

Күз ачып йомган арада ишектән нөгәрләр кереп тулды. Огланнар өстенә үлем арысланнары ташланды, еландай сызгырып кылычлар баш күтәрде, төлкегә ташланган ау лачыны сыман хәнҗәрләр корбаннарына үтеп керде.

Канлы туйда кияү булып утырган хан, эченә тулышкан тантанага чыдый алмыйча сикереп торды да, Танышбәкнең өзелгән башын ишеккә таба тибеп җибәрде.

Үч!

Иң зур ләззәт менә ни икән...

Илһам өчен иң зур мәйдан менә кайда икән...

## 4

— Хан ау урынын карарга китте, ул кайтканчы сөйләшеп алыйк, — диде диван бәге.

— Кайтуга ук кадап үтерергә кирәк, чыдар әмәл калмады, — дип сүзгә кушылды мангыт бәге. — Коңратлар аны якларга җөрьәт итмәячәк. Минем ун төмәнем кылыч күтәрергә әзер тора.

— Бер хәчтерүш дәрвиштән кан калтырап торырга күпме мөмкин! — дип чәчрәп чыкты Котлыбуга. — Әллә без үзебезнең кем икәнебезне оныттыкмы? Бабаларыбызның каны суга әйләндеме? Ул мине кичә бук чүлмәгенә утырган килеш кабул итте!

Берничә морза учлары белән авызларын каплап көлешеп куйды. Котлыбуга моны күреп тагын да кызды, йөзен кызыл тимгелләр басып китте.

— Нигә көләсез, сакалсыз калгырлары! — дип кычкырды ул. — Сарайдагы барлык шагыйрьләрне, дәрвишләрне далага көтүче итеп куды, күрдегезме? Чират хәзер әмирләргә җитә. Мондый мыскылга татар чыдармы?

Барысы да кара коелып, башларын түбән иде. Мәхмүд вәзир сабыр гына сүз башлады:

— Татар чыдам ул. Бу эштә ашыкмаска кирәк. Син, Котлыбуга, Ханикә белән Тогай-Туглы хатын янына барырга тиеш идең. Ничек булды?

— Ханикә аны чын Бирдебәк ди... Ә кортка, әгәр дә ханны богаулый алсак, аның Бирдебәк түгеллегенә таныклык бирергә риза...

— Һе, анасын эт ялагыры, — дип сүгенде мангыт бәге. — Ир астында калгач, аңы бетә хатын-кызның.

— Хикмәт анда гына түгел, — дип янә Мәхмүд вәзир сүзгә кушылды. — Ханикә — акыллы хатын. Ул аны Бирдебәгем, дип Корьән тотып ант итте. Сүзеннән кайтса, аны мөслимә дип кем санга сугар? Икенчедән, бер бичара дәрвиш белән йоклаган хан хатынына сарайда гына түгел, җир йөзендә дә урын калмаячак. Өченчедән, Бирдебәк үтерелсә, ул ханбикәлектән колак кагачак. Аңа артка чигенергә юл юк. Ә инде Җанибәк хатынының әчкерле, икейөзле, кансыз икәнен барыбыз да белә.

— Кадыйбыз да үтерәбез, аларның таныклыгы нигә? — дип кычкырды мангыт бәге. — Сүз боткасы җитәр.

— Аннары... — Вәзир аны тыңламыйча сүзен дәвам итте. — Безгә аны гап-гади дәрвиш дип игълан итү дә ярамый. Чыңгыз канлы огланнар, затлы бәк-морзалар бер хәчтерүшкә буйсынып торган, дип бөтен дөнья бездән көләчәк. Без нәкъ менә Җанибәк углы Бирдебәкне, илгә золым салучы кансыз Бирдебәкне үтерергә тиеш.

— Миңа тәхеттә кем утырса да барыбер, — диде мангыт бәге. — Тик минем кышлауларга, җәйләүләргә генә кагылмасын. Ә бу, анасын ат ниткере, утыз авылымны Кырымга күчереп утыртты.

— Үзе ырусыз булгач, башка ыруларны корытырга уйлый ул.

— Ә кемне тәхеткә күтәрәбез? — диде диван бәге. — Бату хан туруннарыннан берәү дә калмады бит.

— Барысын да кырды, — дип елмайды мангыт бәге. — Ни-ни, кулы каты аның.

— Хәзер чират бәкләргә җитте. — Вәзир каш астыннан гына мангыт бәгенә карап алды. — Кичә генә ике морзаны

ат койрыгына тактырды ул.

— Иртәгә үзен ни көтәсен беркем дә белми, — диде Котлыбуга. — Хан Тәңренең эшенә тыкшына башлады.

— Болгардан Саруҗа кайтканчы эшне бетерергә кирәк. Ул болгар әмирен дарга асып, үзе белән көчле гаскәр алып килә.

Диван бәге тагын үзенең соравын кабатлады:

— Тәхеткә кемне күтәрәбез?

— Аюны әле үтермәгән, тунамаган, ә син инде аның итен өләшә башладың, — диде вәзир. — Тәхет буш тормас.

— Анысы шулай. Үзара бола чыга күрмәсен...

— Әнә Азак буенда Килдебәк җәйли. Аны Үзбәк ханның оныгы дип сөйлиләр...

Мангыт бәге шаркылдап көлеп җибәрде:

— Чыңгыз нәселеннән дип теләсә нинди көтүчене тәхеткә мендерергә була. Инде безнең тәҗрибә бар.

— Ханны ау вакытында укка алырбыз, — дип сүзгә нокта куйды вәзир. — Һәрберебез. Аны аерым кеше үтерергә тиеш түгел. Амин.

Дога кылып барысы да урыныннан кузгалды.

Шулвакыт тышта урам ташларына бәрелеп тояк тавышы яңгырады.

— Кемдер безне тыңлап торган, ахрысы, — дип пышылдады диван бәге. Аның йөзе агарып чыккан иде. Бәкләр шикләнешеп бер-берсенә караштылар. Мангыт бәге иң беренче аңга килеп ишеккә ташланды, тышта аның «Куып җитәргә!» — дигән боерыгы яңгырады.

Вәзир әллә ишләренә, әллә үз-үзенә авыз эченнән мыгырданып куйды:

— Артка юл юк, Ходай ярдәм бирсен.

... Иртә таңнан ук Алтын таш тирәсе кайнап тора иде инде. Елкычылар дирбияләрне, арбаларны карыйлар, чатырчылар киергеләрне, уыкларны барлый, аучылар коралларын тикшерә, кошчылар ау кошлары куна торган тургачларын җилкәләренә салган иде.

Сарайдан чыгарга торганда, ханга аны Котлыбуганың күрәсе килүен әйттеләр.

— Керсен, — дип кул селтәде ул.

— Нинди ашыгыч йомышың бар? — Кулын күкрәгенә кушырып бөгелә-бөгелә кергән бигә хан яратмыйча карады.

— Фетнә, олуг хан! — дип фаҗигале тавыш белән сүз башлады Котлыбуга. — Вәзирең Мәхмүд, мангыт бәге, диван бәге сине ау вакытында укка алырга телиләр.

— Шул гынамы? — Әхмәд мыскыллы елмайды. — Шундый вак-төяк белән минем хозурга керергә ничек җөрьәт иттең, көчек?!

— Ни-ичек? — дип тотлыкты гаҗиз калган Котлыбуга.

— Син дә шулар белән идең бит. Вакыты җиткәч, ыштан төбенә җибәрдеңме?

— Синең өчен гомерем жәл түгел, — диде Котлыбуга батыраеп.

— Буш вәгъдәләр бирмә. Гомер комарлы уен ул, сезнең кебекләрнең аннан аерыласы килми. Ә миңа... Миңа, димәк, үлем шигырен язарга вакыт җиткән.

Ул, үз уйларына бирелеп, беравык тын утырды.

— Син күпме кешенең җанын кыйдың, кан исеннән исердең. Бервакытта да шул үлемне үзең татып карыйсың килмәдеме? Әллә син арый белмисеңме? Кеше башы таудагы таш кебек, берсе кузгалса, үзе артыннан башкаларны да ияртә.

Чарасыз калган Котлыбуга ни дип җавап бирергә дә белмәде.

... Нөгәрләр җанлы коршау булып ау урынын чолгап алганнар иде. Хан бүз тойгынының[10] тумагын[11] салдырды, ау кошы ук кебек һавага атылды. Аннары башка биләр, морзалар да үз кошларын һавага чөйделәр. Бараклар[12] алга ыргылды. Бу тере коршаудан, кабан дуңгызларыннан кала, бер җәнлек тә үтеп чыгарга тиеш түгел иде.

— Ау уң булыр, Аллаһы боерса, — диде Мәхмүд вәзир.

Хан көлде:

— Зур ерткычны алырга уйлыйсың, Мәхмүд!

Вәзирнең тезген тоткан бармаклары агарып китте, әмма йөзе таш кебек салкын иде, анда бер сызык та селкенмәде.

— Кулың калтырамасын, — диде хан.

— Минем бу кадәр тыныч булганым юк иде әле.

— Җәяңне күтәр алайса! — дип кычкырды хан һәм атын камчылап алга ыргылды.

Аның артыннан шунда ук өч ук очты, бераз гына соңарып аларга дүртенче ук кушылды.

Хан иярennән бераз калкынгандай итте, әмма аумады, аркасына кадалган укларны сындырып ат яурынына чалкан ятты.

Акыллы ат, җайдагының авырайган гәүдәсен тоеп, туктап калды. Аның янына беренче булып килеп җиткән мангыт бәге яман сүгенеп кылычы белән үлгән ханның башын кисеп алды. Канга баткан җирән сакалыннан умырып тотып, кисек башны өскә күтәрде.

Әхмәднең зәңгәр күзләре зур итеп ачылган һәм алар, нидер күргәндәй, түм-түгәрәк күк йөзенә гаҗәпләнеп текәлгәннәр кебек иде.

Вәзир килеп ике бармагы белән ханның күз кабакларын төшерде, башны ияр капчыгына салды.

Ау тәмам иде.

Далбай[13], давылбаз[14] тавышын ишетеп, ау кошлары тургачларына кайтып кундылар.

Ханның бүз тойгыны гына алар арасында күренмәде. Ахрысы, ул бәхетсез шагыйрьнең һәм бичара ханның җаны булып күкләргә ашкан иде.

октябрь, 1996

[10] бүз тойгын — ак карчыга

[11] тумак — ау кошы башына кидерелгән калфак

[12] барак — ау эте

[13] далбай — ау кошларын чакыра торган быргы

[14] давылбаз — ау кошларын чакыра торган барабан


Рәссам Фиринад Халиков Донецк шәһәрендә 1957 елның 28 августында туа. 1972-1983 елларда Киров шәһәренең сәнгать училищесында белем ала. 1989 елдан СССР рәссамнар берлеге әгъзасы.

1992 елдан республика, төбәк, гомумрәсәй һәм халыкара күргәзмәләрдә даими катнашып килә. Чит илләрдә — Франция, Испания, Германия, Польша, Тунисста да Фиринад Халиковның картиналарын яхшы беләләр.

1992-96 елларда Рәсәй Нәкыш Академиясенең иҗади остаханәсендә белем ала. Иҗади җитәкчесе — Харис Абдрахман улы Якупов.

Иң яраткан жанры — пейзаж.

Соңгы елларда тарихи темага иҗат итә.



# Тарихка җан өреүче

*«Идел». Фиринад, тарихи темага картина язу бик зур белем сорый: тарихчы да, этнограф та булырга кирәк. Син Татарстаннан читтә туган, читтә укыган егет. Татар тарихы белән ничек кызыксынып киттең?*

Ф.Халиков. Казандагы иҗади остаханәгә йөри башлагач (андый остаханәләр башка шәһәрләрдә дә бар, мәсәлән, Мәскәүдә), тарих белән кызыксына башладым. Татар тарихы белән. Рәссам осталык туплагач күңеленә, рухына якын берәр тема үзләштерергә тиеш. Әмма мәсьәлә анда гына түгел әле. Мин — реалист рәссам. Тарихны реалистик алым белән генә чагылдырырга мөмкин. Икенчесе дә бар: татар тарихы өчен борчылам мин. Урыс рәссамнары үз тарихларын яктырткан күп картиналар иҗат иттеләр. Безнең тарих урысныкыннан ким түгел. Шулай да картиналар аз. Соңгы чиктә, Казанның гөрләп торган, дәүләте булган вакытын да күз алдына бастыра алмыйбыз. Менә шул уйлар мине тарихчы галимнәр белән таныштырды (мәсәлән, Альфред абый Халиков белән). Болгарга бардым. Археологик казу эшләрендә катнаштым. Күп итеп рәсемнәр ясадым. Университетка, Фәннәр академиясенә лекция тыңларга йөрдем. Шулай итеп, өч ел буена материал туплау белән шөгыльләндем. Чыннан да, тарихны белмичә тарихи картиналар иҗат итеп булмый икән ул.

Барсы да тиз генә, җиңел генә хәл ителмәде. Мәсәлән, эскиз ясыйм да, галимнәргә күрсәтәм: йә мәчет үз урынында түгел, йә тау тәбәнәгрәк булып чыга. Унлап эскиз ясарга туры килә иде. Эзләп тапмаганны үзем уйлап чыгарган чаклар да булды.

*«Идел». Казан ханлыгы чорыннан битәр тагы кайсы чорлар белән кызыксынасың?*

Ф.Халиков. Соңгы эшләремнең берсе узган гасыр ахырындагы Казан каласын күз алдына китереп бастыра. Урыс кышын озату, базар, бәйрәм — Казан кайный.

*«Идел». Фиринад, нинди хыялларыгыз бар?*

Ф.Халиков. Татар ханын тәхеткә утыртып ясыйсым килә. Эскизларым әзер инде.

*«Идел». Кайсы ханны?*

Ф.Халиков. Мәскәүдә Иван Грозныйның бер тәхете бар, ул Казан ханы тәхетенә бик тә охшаган... Эшләнеше шул хакта сөйли. Мөгаен, тәхеткә Сафа Гәрәйне утыртырмын, урыс илчеләрен кабул иткәнен сурәтләрмен.

*«Идел». Фиринад, татар ханын татар тәхетенә кабат утыртырга алынганың өчен рәхмәт.*

ХИКӘЯ

# ЙОКЫГА ТАЛГАН

Авылда тирес ташып, утын ярып физик хезмәткә күнеккән Габделфәртнең, шәһәрдә яңа эшкә урнашуга ук, кинәттән генә эче поша башлады. Аңардан да битәр мондагы кәгазь эшенең мәгънәсез, кирәксез икәнен аңлау ачуын чыгарды. Берәр атна эшләп алганнан соң: «Эше дә, акчасы да юк моның, башкалар вакытларын заяга уздыралар, мин кемнән ким әле?!» — дип кулын кесәсенә тыгып йөри башлады. Туктаусыз телефоннан гәрләшүләр, коридор башына чыгып, тәмәке пыскытып, ләчтит сатулар гадәти хәлгә әйләнде. Бер бүлмәдә утыручы Харис абыйсы белән чын-чынлап дуслашып, эч серләрен сөйләшеп алырга да вакыты күп кала иде әле аның. Харис ага үз гомерендә бер тапкыр гына өйләнеп, хәзер карчыгы белән өч ир бала үстереп ята иде. Азып-тузып йөрмәгән, хәләл җефетенә бер тапкыр да хыянәт итеп карамаган абзыйның бу мәсьәләдә фикере катгый иде: хатын-кыз иң әлек ана булырга тиеш, булалмаганнары, булырга теләмәгәннәренең ул гүзәл исемне йөртергә хаклары юк. Бүген икәү коридор башында тәмәке тартып торганда төз гәүдәле, озын буйлы, сыланып торган джинсы чалбар кигән, мәрмәр кебек ак йөзле чибәр кыз пәйда булды. Ирексездән сүзсез калдылар, аңа текәлделәр. Ә кыз, ирләргә таба матур итеп бер елмаеп алды да, алар янына җитәргә бер-ике адым гына калгач, кырт борылып, ишеге ачык торган бер бүлмәгә кереп китте. Андый чибәр туташларга битараф калырга яратмаган Габделфәрт:

— Кем бу? — дип сорады. Харис тиз генә җавап бирергә ашыкмады. Тәмәке төтененә буыла-буыла «черт-черт» итеп берничә тапкыр төкереп алды да:

— Йоклый торган гүзәл кызыбыз шушы була инде безнең! — диде. — Бездә эшли ул... Курьер...

— Ә ни өчен син аны «йоклый торган» дисең?

— Анысын инде, энекәш, ике төрле мәгънәдә аңларга була: беренчедән, бик каты ялкау, эшләгән эшенең рәте-чираты юк, икенчедән, теләсә кем белән йоклап йөрүче ул.

— Йә, кем белән йоклаганын күргәннәр соң аның?

— Соңгы вакытта шеф белән.

— Шеф белән?! — дип шаккаткан булды Габделфәрт. — Соң пенсия яшендә бит ул, карт бит инде ул!

Харис тәмәке төпчеген, төкереге белән сүндереп, чүп савытына ыргытты да, тавышын аз гына түбәнәйтеп, гыйбрәтле иттереп:

— Син, энекәш, шуны аңла, — диде. — Фахишә өчен «ул — карт», «ул — инвалид» дигән төшенчәләрнең әһәмияте юк, аңа акча гына түләсеннәр!

Кызның шундый азгын зат булып чыкканына күңеле төшеп, Габделфәрт шактый вакыт сөйләшмичә торды.

— Кара аны! — диде Харис кисәткән кебегрәк. — Бу озын чәчнең кармагына эләгә күрмә!

Сөйләшә-серләшә бүлмәгә уздылар. Әлеге «йоклап йөрүче гүзәл» — Эльвира атлы икән. Директор хатыны, ишетеп җәнҗал куптаргач, карт түрә хәзер кызга сәлам бирергә дә куркып йөри икән.

Харис кыз турында тагын нидер сөйләргә генә торганда, тестр аша аны директор үзенә чакыртып алды.

Габделфәрт, ни белән булса да шөгыльләнүдән ваз кичеп, уй-хыялларына чумып утырды. Ул үзе дә өйләнгән кеше, ике баласы бар. Хатыны Нәсимәгә бай туганнары шәһәр җиреннән искерәк кенә йорт

# АХИР

# ГҮЗӘЛ

алып бирмәсә, Габделфәрт гомерендә дә авылыннан китәсе кеше түгел иде.

Ярата микән соң ул Нәсимәсен? Ходай белсен! Авыл җирендә утыздан узгач та буйдак егет булып яшәүнең бигүк килешеп бетмәгәнен аңлаганга гына өйләнеп караган иде дә ул — шуннан бирле гаилә тормышына тартылды, чит хатыннар артыннан да чапмады.

Иртәгесен Харис бер айга командировкага китеп барды. Габделфәрт бүлмәдә үзе генә калды. Калын тышлы кызыл папка эченә тутырылган эш кәгазьләрен ачып таратырга да өлгермәде, теге «гүзәл шәхес» килеп керде. Кызда оялып-нитеп, тартынып тору гадәте юк иде, күрәсең, туп-туры Габделфәрткә таба атлады. Аның йөрешендә дә, үз-үзен тотышында да гади тел белән генә аңлаталмаслык сер ята иде.


Кыз рөхсәтсез-нисез каршыга килеп утыргач, Габделфәрт, ни дип әйтергә белмичә, бер мәлгә җебеп төште. Кыз чынлап та чибәр. Ләкин аның ул матурлыгы инде кемнәрдер тарафыннан кисәкләп-кисәкләп өзгәләнгән, күңел назлары өлешләп-өлешләп таратылган, черегән яфраклар өеменнән аңкыган көз исе сыман, аңардан тәкәббер салкынлык, күңел кайтаргыч битарафлык бөркелеп тора иде.

Тиз генә танышып алгач, кыз тартырга сорады.

— «Идел» генә шул, — диде Габделфәрт, уңайсызланып. — Башкасы юк...

— Әгәр сез миңа ун мең тәңкә биреп торсагыз, мин яхшы сигарет табып керер идем, — диде Эльвира, матур, тигез тешләрен балкытып.

Габделфәрт әбәткә дип хатыныннан алган акчасын чыгарып бирде. Эльвираның йөзе тагы да як-



тырып китте. Габделфәрт ягына: «Мин — синеке, тик әлегә ашыкма!» — дигән сыман, вәгъдәле караш ташлап урыныннан күтәрелде.

— Ә сез хатын-кызның матурлыгын нидә күрәсез? — дип кинәт кенә җитди итеп сорап куйды кыз.

— Беләсезме, матурым, — диде Габделфәрт, бер дә аптырап тормыйча сафсата сата башлап. — Хатын-кызның матурлыгы аның, әйтик, кигән киемендә дә, матур йөрешендә дә түгел, ә күз карашында. Ә күз карашы берничә төрле була...

Эльвира, аның сафсатасын тыңлап бетерергә теләмичә:

— Тиздән керермен, әңгәмәбезне дәвам итәрбез! — диде дә, чыгып юк булды. Шуннан соң Эльвира ике көн күренмәде.

Габделфәрт тормыш мәшәкатьләренә чумып, «гүзәл»нең барлыгын да оныта башлады. Тик өченче көнне ул тагын пәйда булды.

— Илле тәңкә акча кирәк, табалмассызмы? — дип мөрәҗәгать итте ул. — Берәр чит ил шәрабы табып, ял итеп алырга уйлыйм.

— Ул кадәр үк юк шул миндә, — дип мыгырданды Габделфәрт кесә төпләрен каккалап.

— Бергә утырыр идек.

Бар акчасын кырып-себереп хатынына биреп барган Габделфәрт тагын бер кат иңнәрен җыерып, «юк» дип җавап бирде.

— Әгәр каршы килмәсәгез, мин сезнең өчен берәрсеннән бурычка алып торалам, — диде Эльвира сынаулы караш ташлап.

— Ал, алайса, соңыннан үзем түләрмен, — дигән булды ул.

— Миңа барырбыз, тулай торакта минем бүлмәм бар, үзем генә торам, — дип сөйләнде кыз, ир-егетнең яшертен теләген кабызып.

Кирәкле сумма бик тиз табылды. Кибеткә кереп, аракысын, ашамлыгын алганнан соң Эльвираның торган җиренә киттеләр. Таныш кешеләр очрамасын дип як-ягына карангалап барган Габделфәртнең исенә Харис абзыйның: «Кара аны, аның кармагына эләгә күрмә», — дигән сүзләре килеп төшсә дә, кире уйларга соң иде инде...

Соң иде... чынлап та, соң иде. Агач каусәләреннән аяк астына шыбырдап сары яфраклар коела, әбиләр чуагында гына була торган илаһи иркенлек, наз, җылылык, янда гына барган яшь, сөйкемле, гүзәл кыз күпне, бик күпне вәгъдә итә иде шул Габделфәрткә...

Эльвира яшәп яткан тулай торак берничә секциягә бүленгән. Һәр секциядә биш-алты кечкенә бүлмә. Кызның бүлмәсенә үткәндә каршыларына сипкелле ямьсез бер кыз очрагач: «Үзе генә түгел икән, иптәш кызы да өйдә икән!» — дип уйлап алды Габделфәрт, инде ник килгәненә үкенә башлады. Тик, бәхеткә каршы, кыз икенче бер бүлмәгә кереп китте, Эльвира үз бүлмәсен ачып керде. Бүлмә буш, әле шуның өстенә һич көтмәгәндә җыйнак, пөхтә булып чыкты. Чикләвек төсендәге полировкалы дәү шифоньер бүлмәне икегә бүлеп тора. Түрдәрәк киң агач софа, икенче якта ишектән керүгә үк аш өстәле, шуның янында ук китап киштәсе — Достоевский һәм Писемский томнары тезелеп киткән. Стена буйлап Майкл Джексон, Мадонна рәсемнәре ябыштырылган аш өстәлендә Мәһдиевнең әле яңа басылган өр-яңа китабы аунап ята. Эльвира, китапны читкәрәк этеп, алып кайткан әйберләрне өстәлгә тезеп чыкты да, Габделфәрткә утырырга тәкъдим итте.

Кысылып кына өстәл белән стена арасындагы урындыкка кереп утыргач, кунак бүлмә эчен тагын бер кат күздән кичерде.

— Менә шушында яшәп ятам инде мин, — диде кыз, сигарет кабызып.

— Шәп! Искиткеч! — дигән булды Габделфәрт.

— Теләсәң, минем софа белән таныша тор, — дип астыртын гына елмаеп куйды Эльвира, шаярткан булып.

Габделфәрт, яшертен теләгән туташка тиз генә ачып салудан сакланып, итагатьле генә елмайды да, шешәне ачып бокалларга шәраб тутырып куйды.

— Миңа бөтен кеше Эля дип эндәшә, син дә шулай гына эндәш...

— Яхшы, Эля...

— Йә, нәрсә өчен эчәбез соң?! — диде Эля, тәмәке төпчеген көллеккә ташлаганнан соң, шәраб тулы бокал күтәреп.

— Беләсеңме, Эля, — диде Габделфәрт, бокалын чәкештереп. — Соңгы вакытта, белмим, мин нигәдер бик арыдым, гаиләдән, тормыштан, ыгы-зыгыдан дисеңме... Синең янга нәрсәдер алыр өчен генә килгән дип уйлама, юк, мин чынлап арыдым... Менә шуңа күрә дә синең белән шулай кара-каршы утырып, ял итеп аласым килгән иде! Әйдә, синең исәнлеккә!

Кызга тост ошады булса кирәк. Кунакка шашардай булып бер карап куйды да, куе итеп помада яккан бөрмәле иреннәрен шәрабка тидерде.

— Ә син үкенмисеңме? — дип сорап куйды кыз, берничә йотым капкач. — Син минем өчен бурычка баттың...

— Нинди үкенү, нинди бурычка бату ди инде, просто мин сиңа бәйрәм ясарга теләдем...

Берәр бокал эчемлек йотканнан соң икесе дә йомшарып, иркенәеп киттеләр. Габделфәрт ашардай булып кызга карап алды да:

— Эля, сине үбәргә ярыймы? — дип сорады.

— Кунак булып килгәнсең икән, тыйнак бул! — дип кырт кисте кыз. — Мин ниндидер «дешевка» түгел! Бер генә мисал китерәм, тыңла. Минем бер танышым бар иде, кстати, беренче егетем, голубая кровь была у него, ну в общем красавец! Ә ул минем өчен нәрсә генә эшләмәде, нинди генә капризымны үтәмәде! Ресторандыр, гостиницадыр, күңел ачудыр, сәяхәттәр — боларның барысы да булды минем гомеремдә. Ярата иде ул мине! Тик хатыны бар иде. Аны аерып миңа өйләнергә дә исәбе юк түгел иде, тик хатынын барыбер миннән өстенрәк күрде. Шун-

дый кайфны татыганнан соң кемгәдер кияүгә чыгу турында хыяллану ахмаклыктыр, билгеле...

— Бай идемени?

— Майкл Джексон бүләк иткән магнитофонга кадәр бар иде аның коллекциясендә... — О!

— О шул! Минем турыда начар уйлама, мин үземнең бәямне яхшы беләм. Урам кызлары кебек юкбарга алданып йөрмим мин...

Эльвираның ясалма тәккәбберлеге Габделфәртнең эчен пошыра башлады.

— Син, димәк, супер-девочка буласың инде?!

Эля дәшмәде. Бер сигаретын сүндереп икенчесен кабызды. Габделфәртнең тик торганнан гына ачу чыкты. Моннан китү хәерлерәк иде. Тик китәр алдыннан, Эляның нервысында уйнарга теләп, болай диде:

— Беләсеңме, матурым, үзеңне әллә кемгә куя башладың бугай, синең урында бераз тыйнаграк булырга кирәк иде...

— Син бу сүзләрең белән мине түбәнсеттең, рәнҗеттең, — диде Эля, иреннәрен турсайтып. — Нәрсә такылдаганыңны беләсеңме, юкмы?!

Кыз белән кинәт кенә ачуланышып китүдән куркып Габделфәрт тын калды. Үпкәләшеп озак кына сүзсез утыргач, Габделфәрт түзмәде, гафу үтенергә тотынды.

— Акыллы да, чибәр дә син... Шулай да, син мине дә аңла инде, әзрәк жәллә инде...

— Ә ни өчен мин сине жәлләргә тиеш ди?!

— Бер генә тапкыр булса да үптер инде, матурым, яме!

— Ни-ни! — дип кенә куйды кыз, янә бокалына ябышып. — Минем чын бәһамнең күпме торганын беләсеңме соң син?!

— Күпме?

— 150 доллар...

— Күп түгел икән, — дип көрсенеп куйды Габделфәрт. — Сине бик темпераментлы дип сөйлиләр, дөресме шул? — дип сүзне икенчегә борырга өлгерде кыз.

— Кемнәр?

— Эштәгеләр...

— Ә алар каян белсеннәр, — дип акланырга тотынды Габделфәрт. — Эштә минем синнән башка беркем белән дә якыннан аралашканым юк.

— Ә минем турыда ни сөйлиләр?

— «Йоклый торган гүзәл кыз», диләр, спящая красавица ягъни...

— Кеше генә шундый сүз чыгара, ә асылда миннән дә чиста, инсафлы кыз юктыр да әле ул оешмада!

«Һаман да аклана, һаман да үзен чиста итеп күрсәтергә тырыша бит бу җүнсез кыз, — дип ирексездән уйлап алды Габделфәрт. — Ул бит минем белән әнә теге агач софада аунарга тиешле...»

— Дөресен генә әйткәндә, — дип дәвам итте кыз, — йоклый торган кыз ул бит әле очраган бер ир заты белән йоклап йөрүче түгел...

— Син сайланма кешеләр белән йөрисең инде, ә?! — дип төрттереп алырга өлгерде Габделфәрт.

— Шундый бер әкият бар, — дип сөйләп китте Эля, Габделфәртнең соңгы сүзләрен колагына да элмичә. — Кыз белән егет бер-берсен бик тә яратканнар ди, гомергә бергә булырга сүз куешканнар. Туй көне билгеләнгән. Тик шул туйга, гөнаһ шомлыгына каршы, җен карчыгын чакырырга онытканнар. Ә карчыкның моңа бик тә ачуы чыккан. Ике яшь йөрәккә үч итеп кызны мәңгелеккә йокыга талдырган. Егет бу хәлгә бик тә аптырый, тик кызны шул йоклаган хәлендә дә яратудан туктамый, мәхәббәткә тугры булып кала. Ни хикмәт, егетнең кайнар мәхәббәте кызны кабат terелтә. Җен карчыгы җиңелә. Ә кыз белән егет, бер-берсен тагы да көчлерәк яратып, озын-озак гомер кичерәләр...

— Бу әкиятең белән син миңа нәрсә әйтергә җыенасың?

— Син дә мине шул әкияттәге егет кебек ярата алыр идеңме?

— Мин сине яратам...

— Ә хатының? Балаларың?

— Хатын — хатын, бала бала инде ул...

— Аларны ташлап миңа өйләнер идеңме соң?!

— Кияүгә чыгарга теләмәгән хатын-кыз бармы икән бу дөньяда! — диде Габделфәрт, канәгатьсезлек белән урыннан күтәрелеп.

— Китәсеңме? — дип сорады Эля, егетне үзенә дәшеп торган җылы караш белән сыйлап. Аның җылы карашыннан эреп киткән Габделфәрт:

— Әз генә үптер инде, Эля, иренең читеннән генә булса да! — дип ялварды.

— Читеннән генә?

— Әйе, читеннән генә...

— Читеннән генә булса, мөмкин, сөеклем, мә! — дип Эля аңа яңагын куйды.

Габделфәрт башта аның битеннән үпте, аннан иреннәренә үрелде. Тик рәхәт якынлыктан исереп кызны кочаклап үзенә таба тартып китерәм дигәндә генә кыз, аның кочагыннан ычкынып, үбешүнең рәхәтен качырды.

— Кайчан да булса, бәлкем, мин синеке булырмын, тик аның өчен вакыт кирәк, вакыт, — диде ул, кәефе киткән Габделфәртнең күзенә туп-туры карап.

Шундый уңышсызлыкка тарыганнан соң бу «гүзәл» белән башка очрашмаска дип үз-үзенә сүз куйса да, Габделфәрт сүзендә торалмады. Эляның ирләргә тәэсир итү көче Габделфәртнең гади кирелегеннән көчлерәк булып чыкты — килеп сүз кушуга ук Габделфәрт эреп китә торган иде. Кызны көйли-көйли ул муеннан бурычка батып бетте. Өенә акча алып кайтудан туктады. Кесәсе бөтенләйгә бушап калгач ул Элядан качып йөри башлады. Андый вакытта Эля аны үзе таба, күңелен күрә белә иде. Көннәрдән бер көнне Эля Габделфәртне тагын үзенә кунакка чакырды. Хуҗасына ияреп йөргән эт кебек, Габделфәрт тагын Эляга иярде. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, кирәк-яраклар алып кибеттән чыгып барганда аларга Габделфәртнең хатыны Нәсимә

очрады. Әллә күзәтеп йөргән, әллә шулай туры килгән... Тик хатынын күрүгә Габделфәрт шундук коелып төште, телсез калды.

— Габделфәрт, син кая? — дип эндәште Нәсимә, каршыларына шулай тиктомалдан килеп чыкканына үзен берникадәр гаепле сизеп.

Ирексездән Габделфәрт Эля белән Нәсимәне чагыштырып алды. Җир белән күк арасы. Нәсимәнең арыган, талчыккан, җыерчыкланган йөзендә ниндидер курку галәмәтләре бар. Тормыш мәшәкатьләреннән, үз-үзенә артык игътибар итә алмау сәбәпле картаеп, сыгылып төшкән. Кияүгә чыгып, икеөч бала тапкан хатыннарның ямьсезлекләрен, ирсез калудан, балаларын әтисез калдырудан килгән аңлый алмаслык бер эчке курку да көчәйтеп тора иде. Өстенә кигән сары махер кофтасы да бу минутта аны Эля каршында бизәми, киресенчә, үзенең генә түгел, иренең дә абруен төшереп тора сыман. Кызгану хисеннән башка бер генә хис тә уяталмый иде аның хәләл җефете. Заманча киенгән, ир затларын бөтен нечкәлекләре белән үзенә җәлеп итеп торган, чиста ак йөзле, күркәм йөрешле Эля янында юеш судан чыккан чебеш бәбкәсен хәтерләтә иде ул... Ә бит алар яшьтәшләр.

Габделфәрт Эляга елышып барган җиреннән берникадәр читкә авышты. Эля, бу хәлгә артык исе китмәгәндәй, «Мин сине көтәм, чибәрем!» дигәндәй, Габделфәрткә астыртын гына карап елмайды да, юлның икенче ягына чыкты.

— Уйлаган идем аны...

Нәсимә сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Габделфәрт ярсып хатынына ташланды.

— Ә син мине тикшереп йөрисең, йә, кая дөреслек, йә, кая ирек?! — дип кычкыра башлады ул.

— Юк, мин баланы бакчадан алып кайтырга гына чыккан идем, — диде Нәсимә, иренең һөҗүменнән каушап калып...

— Ялганлама, бала алырга иртә әле! — дип җикеренде Габделфәрт. — Өйләнгәннән бирле, слушай, канымны эчәсең, кит, югал юлымнан, мин бу кызны яратам, бу кызга мин өйләнәчәкмен!

— Ә балалар? Алар синең балалар түгелмени?! — дип елап ук җибәрде Нәсимә.

Тавышка тирә-яктагылар игътибар итә башлагач, Эля, иреннәрен турсайтып алар ягына бер карап алды да өенә атлады.

— Балаларны син таптың, син кара да инде! — дип кычкырды Габделфәрт хатынына һәм, аның белән артык сөйләшеп торуны кулай күрмичә, Эля артыннан иярде.

— Мин сине көйләмим, нишләп иярдең, хатының белән каласың бар иде?! — диде Эля, Габделфәртнең үзе артыннан ияргәнен күреп.

Бәйрәмчә башланган очрашуның яме киткән иде инде. Шулай да, Габделфәрт Эля артыннан калмады. Хатыны ягына борылып карарга да куркып, ул мышный-мышный, мырлый-мырлый «гүзәле» артыннан барды...

Тик менә бергә барырга тәки насыйп булмады аларга. Юлларын аурупача киенгән ике әзмәвер егет кисте. Алар Эляның элеккеге танышлары булып чыктылар. Ябыграк чырайлысы кызны хәтта кочаклап ук алды һәм юл кырына гына килеп туктаган кара «Вольво»га өстери башлады. Эля, каршы килүнең артык икәнен аңлап, ясалма елмаеп, егеткә иярде. Габделфәрт, бу шикле егетләрдән баштарак шүрләп калса да:

— Эля, мин сине беркая да җибәрмим! — дип әйтмичә булдыра алмады.

Ябык чырайлысы тазарагына «Аңлаш егет белән» дип кыска гына ишарә ясады да, Эляны кочаклап машинага кереп утырды.

— Мин сине аңлыйм, тик һәрнәрсәдә, теләсәң уртак тел табарга була, — дип сөйләштерә-сөйләштерә, таза чырайлысы Габделфәртне биек йортлар арасында югалып калган ташландык парк эченә алып кереп китте.

Габделфәрткә иң элек арттан каты итеп муен тамырына китереп тарттылар, ул, башын да селкетә алмыйча, сеңеп, катып калды. Ә йодрык белән аңын югалтырлык итеп чигәсенә сукканнан соң исә, Габделфәрт, гөрселдәп, кирпечтән түшәлгән салкын тротуарга ауды.

Аңын җуйган Габделфәрт, калтырана-калтырана, таң атар алдыннан, юеш салкын яңгыр сибәли башлагач кына уянып китте. Каерылып миләш төлгәшләре өстенә авып төшкән парк капкасыннан ашыга-ашыга кереп барган Эляны күргәч ул үз-үзенә ышанмыйча карап торды...

— Габделфәрт, җаным, бәгърем! Исәнме син?! Төне буе синең өчен ут йотып чыктым, тик мине җибәрмәделәр, хайваннар! Кичер мине, мин гаепле, минем аркада гына, — дип тәкрарлый-тәкрарлый Габделфәрткә үрелде.

— Акрын, буяласың бит! — дип, ул Эляны читкә этәрде.

— Киттек, әйдә, безгә, җылынырсың, юынырсың! — дип, Эля бернигә дә карамыйча Габделфәртне култыклап алды.

«Мин монда чарасыз салкын җир өстендә тәгәрәп ятканда син шул мине кыйнаган жлоблар белән җылы урын өстендә тәгәрәшкәнсең, имансыз!» — дип әйтмәкче булган иде Габделфәрт, тик кызның ихласлыгына, ялганламаганына чын күңеленнән инанып, тыелып калды...

Габделфәртне әле алай беркем дә яратканы булмады. Аларның мәхәббәтләре чын Сөю тантанасына әйләнсен өчен барлык киртәләрне дә җимереп ташлаган гүзәл кызның иркәләү-назлавыннан Габделфәрт тәмам башын югалтты. Бөтен эчке каршылыкларны, андый четерекле вакытта ир белән хатын-кыз арасында була торган уңайсызлануларны бердәм җиңеп, алар төпсез сөю чоңгылына ташландылар. Мәхәббәт уенына бирелгән ике яшь кеше дөньяның язылмаган кануннарына битараф калып, бер көн, бер төн буе онытылып, бер-берсен соңгы

тапкыр яраткан кебек яраттылар...

«Фахишә диләр, соң фахишә болай ярата аламы соң?!» — дип уйлады Габделфәрт, кызның шәрә тәненнән, аякларыннан, тез башларыннан иркәләп.

Алар иртәгесен таң алдыннан гына хушлаштылар. Тәнендә ниндидер рәхәт арыганлык, җанында бушлык сизгән Габделфәрт Эля белән тиз-тиз генә саубуллашып, өенә кайтып китте. Хәләл җефете алдында үзен бик тә гаепле сизгән ир фатир ишеген курка-курка гына үз ачкычы белән ачып керде. Тик хатыны уянган, балалар да йокыдан торып өй борынча чабышып йөриләр иде инде...

Ни хикмәт, хатыны аңа бернинди дә үпкә белдермәде, ә киресенчә, рәнҗешен, ачуын тирәнгә, эчкә яшерергә тырышып, тыныч кына:

— Син ипи алып кайтмагансыңдыр? — дип сорап куйды.

Габделфәрт шатлыгын, хатынына булган якынлык хисләрен яшерә алмыйча, Нәсимәне бер кочаклап үпте дә, аңа башка бервакытта да хыянәт итмәскә сүз бирә-бирә, ипи кибетенә йөгерде...

Харис абый командировкадан кайткан гына иде. Габделфәртнең маҗараларын кемнәндер ишетеп өлгергән абзый аны:

— Нәрсә, теге гүзәлнең тәки кармагына эләктең мени? — дигән сорау белән каршы алды.

Габделфәрт, кыза-кыза, Эляны якларга тотынды. Харис абзые аның саен елмаеп, көлеп кенә торды.

— Уйлап кара, — диде Габделфәрт, ирексездән фәлсәфәгә бирелеп — Эля кебек япь-яшь кызлар авылдан шәһәргә киләләр. Аларны ни көтә соң монда? Кайсылары кияүгә чыгу бәхетенә ирешәләр, ә чыга алмаганнары Эля юлына басарга мәҗбүр булалар. Бөтен гаепне дә шушы мескен кызлардан эзләргә кирәкмидер. Эля кебек ярата алучылар да сирәк, безнең хатыннарга алардан күп нәрсәгә өйрәнергә кирәк әле...

— Син хаклы, — дип әйтеп куйды Харис, Габделфәртне тәрәзәдән карарга чакырып. — Әнә, синең «гүзәле»ң тагын сәяхәткә җыена, ахрысы?

Чынлап та, проходной каршында Габделфәрткә әле яңа гына бәхетсезлек китергән кара «Вольво» килеп туктаган, ә киенгән-ясанган Эля Габделфәртне кыйнаган таза чырайлының ярдәме белән машинага утырып маташа иде.

— Син дә хаклы, Харис абый, — дип әйтеп куюдан башка сүз тапмады Габделфәрт.

Ә ике-өч көннән соң ташландык бер йортның караңгы подвалында Эляның үле гәүдәсен табып алдылар. Гүзәл кыз мәңгелеккә йокыга талды, ә Габделфәрт тиз генә гариза сырлап бу эшеннән китеп барды.



# Татар морзалары

## Йомышлы татарларның һәм морзаларның 100 фамилиясе

**Илдус ГАБДУЛЛИН**


Дәвамы. Башы 1995 елның 4—11 нче, 1996 елның 1—9 нче саннарында.

**89. Үтәшевләр (Үтешевләр).** Уфа өязендә XYII йөздә яши башлыйлар. 1713 елда Оса юлының Бишалап авылында Тимкә морза Бәйки улы Үтешев яшәгәне билгеле (МИБ, 3 т., 1960. 100-102 б.). XYIII йөз азагында Пенза якларында яшәгән Үтәшевләр Бәләбәй өязенең Каргалы авылына (Благовар районы) күчеп утыралар (БРҮДТА, 138 ф., 2 тасв., 35 сак. бер., 645 б.; 1 ф., 1 тасв., 1343 сак. бер., 49 б.). Пенза губирнасы Краснослободски өязенең Лекенде авылында яшәп калганнары XIX йөздә документларда теркәлгәннәр. Християн дәрәҗәсендә калганнар.

**90. Чанышевлар.** Чыңгыз хан токымы. XYIII-XIX йөзләрдә Шацки (соңрак Тамбов) өязе Тениш авылында яшиләр. 1754 һәм 1759 елларда кенәз Чанышевлар Бәләбәй өязене— Күзәй авылына (Бүздәк районы) күчеп утыралар (РДБАА, 350 ф., 2 тасв., 3798 сак.бер., 125 б.; БР ҮДТА, 172 ф., 1 тасв., 51 сак.бер., 12 б.). Прапорщик кенәз Ибраһим Биктимер улы Чанышев 1777 елда Тамьян волосте башкортларыннан җир сатып ала (МИБ, 5 т., 65-66 бб.). Шуннан соң Чанышевлар Тукай авылында (Бишбүләк районы) яшиләр. Дворянлыкны 1796 елда кайтарып алалар (БР ҮДТА, 1 ф., 1 тасв., 1343 сак.бер., 42-44 бб.). Шәҗәрәләренең бер өлеше: Темген — Чаныш — Чемай — Ишмәмәт — Рәҗәп — Йосыф — Мостафа — Габделкәбир — Якуп — Йосыф — Исмәгыйль — Марат.

**91. Хуҗасәитовлар.** Кар бәк токымы. Бу нәсел Арча районы Түбән Оры авылы белән бәйле. Урыс патшасы Михаил Федорович 1657 елда кенәз Хуҗасәитовка Ашыт елгасы буенда 2442 дисәтинә җир бүләк итә. Хуҗасәитовлар арасыннан күп кенә сәүдәгәр, күнчеләр, комач мануфактураларының хуҗалары чыга (Әхмәтҗанов М.И. 1991, 43 б.; Алишев С.Х. 1984, с.67).

*(Дәвамы киләсе санда)*



# ХАН түгелсең!

* * *

Минем ике авылым бар.

Аның берсе — мине дөньяга тудырган Түреш (Мөслим районы). Икенчесе — балачагым, үсмер чорым узган Олыймән (Актаныш).

Менә шушы ике авыл арасында Яңа Сәет дип аталган тагы бер авыл бар. Яңа Сәет — дөньяга Дәлфәтне, шигърияткә Зөлфәтне биргән авыл.

*...Кое сиртмәләре җырлап тора,*
*Яңа Сәет — татар авылы.*
*Бер соклану белән күзәтәм мин*
*Кызларының текә адымын.*

*Бабаларым монда чана бөккән,*
*Агаларым тәртә каерган.*
*Кул тотынып авыл әйләнәсен*
*Әйлән-бәйлән уйный карурман...*

Түреш белән Яңа Сәетне урман аерып тора. Яңа Сәет белән Олыймән арасында исә басу-кырлар, үр, болыннар (Зөлфәт сүзләренә язылган «Сагынуга дәва юк икән» (З.Гыйбадуллин көе) җырын хәтерлисездер: «Сәет урманнары, Бүләр болыннары»...) җәелеп киткән.

Әгәр Олыймәннең Актанышка таба күтәрелгән үреннән — авыл халкы «Каенлык» дип атаган җирдән Мөслим тарафына караш ташласаң, Яңа Сәет авылы уч төбендәгедәй күренеп тора. Хәтта Яңа Сәетнең күршесе Уразмәт тә шул уч төбенә сыеп бетә...

...Балачакта безнең, бер иш малай-шалайның, вилсәпитләргә атланып күрше авылларга «ил гизәргә» йөри торган гадәте бар иде. Якын-тирәдә без булмаган, без күрмәгән авыллар калды микән: Тәкмәк — Югары Яхшый — Наратлы (бу авыл хәзер юк инде) — Байсар... Айман — Колын — Пучы... Сикия — Әмәкәй...


Бу — үзенә күрә бер мавыгу-кызыксыну, үзебезчә дөнья күрергә тырышуыбыз булгандыр инде. Әтиәниләр мондый сәяхәтләргә чыгуыбызны, бәлки, юкны бушка аударып йөрү дип кенә кабул иткәннәрдер. Хәер, күп очракта алар кайсы авылга барып-кайтуыбызны белми дә кала иделәр. Алдан ук маршрутны билгеләп («Бүген фәлән авылга барып кайтабыз!»), чыгып китәбез сәфәргә, ачыгып, алҗып, хәлдән таеп кире кайтабыз. Әмма бу ачыгу-алҗулар безнең күңелләрдәге шатлыклы тәэсирләр янында бер ләззәтле интегү генә: без бит бүген тагын бер авылны ачтык!

Чираттагы шундый сәяхәтләребезнең берсендә без Яңа Сәет һәм Уразмәт авылларына килеп чыктык. «Менә шушы Яңа Сәет авылында Зөлфәт абый туган инде... Шагыйрь... Менә бу Уразмәт мәктәбендә Зөлфәт абый укыган... Шагыйрь Рәдиф Гаташ аның укытучысы булган...» дигән уйлар, әлбәттә, ул чакта башыбызга килеп тә карамады. Күрәсең, кызыксыну дигән өстенлек ул чагында әдәбиятка түгел, географиягә күбрәк бирелгәндер... Монда, билгеле, кул астыбызда гына үз «техникабыз» (балачагыбызның аерылгысыз юлдашы — вилсәпидне әйтүем инде) булу да зур роль уйнагандыр. Шулайдыр...

Һәрхәлдә, Әдәбият дөньясын, шул дөньядагы Шигърият илен без әле соңрак ачтык. Тагы да үсә төшкәч. Борыннарыбыз кызлар исен сизеп кытыклана

# Ләбиб ЛЕРОН

# Син — Зөлфәт!



Л. Лерон шаржы

башлагач, оялчан күз карашларыбыз таныш чәч толымнарына сихерләнеп ябыша башлагач, күңелләрдәге тәүге хисләр шакмаклы дәфтәр битләренә шигъри сүзләр булып төшә башлагач...

Шигъриятне ачу өчен вилсәпид кирәкми иде инде безгә. Аны мәхәббәт алыштырды...

* * *

... Миңа өч-дүрт яшьләр чамасы чакта, ул — Дөлфәт Маликов, булачак шагыйрь Зөлфәт, хәлфәсе Рәдиф Гаташ фатыйхасын алып, Казан каласы тарафына йөз тотып сәфәр чыккан. Аның күңел төенчегендә — якты хыял-идеаллар, зур өметләр, садә уй-хисләр, язылачы шигырьләр, ирешәсе максатлар, самими үҗәтлек, шөбһәле оялчанлык (Казан аны кабул итәрме?)...

Ул — мосафир. Ә мосафирларның барыр юллары беркайчан да тигез булмый, туры гына булмый аларның барыр сукмаклары. Адым саен сикәлтәдер йә түмгәктер, барган саен — борылышлар, тау менүләр, тау төшүләр, ымсындыргыч Серле Билгесезлек...

Без һәммәбез — мосафирлар. Юл газабы — гүр газабы, диләр. Хак. Шулай. Кайчак булмый таянырга таяклар да, адаштыра юл күрсәткеч маяклар да...

* * *

... Байтак юллар-еллар узгач, ул әйтәчәк әле Шагыйрь-остазына:

*...Соңнан күпме үткелләрне кичтек! —*
*Кемнәр кайда? Дөнья ни хәлдә?*
*Син әйткәнчә, бөек идеаллар*
*Одеалга калды бит, хәлфә!*

*...Кая гына барып чыктык, хәлфәм,*
*Инде кая барыйк, илдәшләр?*
*Без барасы юллар юкка чыкты —*
*Юл өзеге безнең бу яшәү...*

*Әйт, мөгаллим — ник чор чорсызланды?*
*Кара карлар ява күңелгә —*
*Аксакал һәм егет була белгән*
*Чын ир җитми бугай бу илгә...*

* * *

...Аның Казанга килүенә ундүрт ел вакыт үтәр, инде ул шул вакыт аралыгында шагыйрь Зөлфәт дигән исем-ат алыр, «Мәхәббәт», «Йодрык», «Туган тел хакында» һәм «...җилдерде ул дала атларында...» («Чакырылмаган кунак — татардан да яманрак») дигән атаклы шигырьләрен язып дан-шөһрәт казаныр, «Сагынуга дәва юк икән», «Елыйсың, нигә еларга...», «Һаман яратам», «Ашкын, кешем» кебек популяр җырлар һәм «Мәкерле песи» исемле беренче татар балалар операсының либретто авторы булыр...

Әйе, ундүрт ел узар...

Һәм мин инде унҗиде яшьлек егет, Казан университетына укырга керү теләге белән килгән абитуриент, яшьтәшләрем Ркаил Зәйдуллин, Ләис Харрасов (Зөлкарнәй) белән бергә тарих буенча соңгы имтиханны тапшыргач, кала тулай тораkларының берсендә аның белән — Зөлфәт абый белән очрашырмын.

Имтиханнарны уңышлы тапшыру уңаеннан җәһәт кенә оештырылган кечкенә мәҗлесебезгә ул каләмдәш дуслары Фаил Шәфигуллин һәм Фәннур Сафин белән килгән булыр...

Тыйнак мәҗлес башланыр, кунакларга дип алынган коньяктан аз-маз авыз итә-итә мәзәк хәлләр сөйләнер, шигырьләр укылыр, кунаклар безнең кай төбәкләрдән килүебез белән — гәрчә матбугат битләрендә ара-тирә күренгәләгән шигырьязмаларыбыз буенча кай яклардан булуыбызны инде тәгаен белсәләр дә — янә кызыксынып-сораштырып алгаларлар, шулвакыт Зөлфәт абый, Фәннур абый, Ләис һәм мин, һәммәбез бер яктан — бер төбәктәнрәк булуыбыз белән мактанып, шаярып кына масайган булып, Фаил абый белән Ркаилне үртәп, үзара көлешеп алган булырбыз, аннары барчабыз бергә тыелалмыйча, рәхәтләнеп шаркылдарга



Фотосурәтләр Зөлфәтнең шәхси тупланмасыннан алынды

тотынырбыз... Зөлфәт абый сүз арасында гына: «Кыстати, әй, армиядәге дустың турындагы язмаң озакламый «Яшь ленинчы»да чыгачак!» дип миңа куанычлы хәбәр әйтеп куяр... Теле телгә йокмаган Зөлфәт абыйның сөйләгәннәрен тың— лап, кызыклы җирләрендә һәммәбез белән бергә көлеп, әмма күп вакыт тыенкы гына елмаеп утырган Фаил абый да минем тарафка башы белән ишарәләп: «Әле аның бер мәзәге дә тиздән бездә, «Чаян»да басылачак», — дип мине тагы да үсендереп җибәрер.

Бу — 1979 елның 14 августы булыр.

* * *

Әлеге тәүге очрашудан соң без Зөлфәт абый белән, еш булмаса да, туры килгәләгәндә очрашкалыйкүрешкәли башладык. Әлбәттә, иркенләп, җәелеп китеп сөйләшүләргә ерак әле. Вәләкин мин шагыйрьнең иҗатын гына түгел, үзен дә шактый яхшы беләм дип саныйм. Аның да мине шулай белүенә шикшөһбәм юк иде.

Ләкин...

Беркөнне шулай, Ркаил белән икәү, әле «Татарстан яшьләре», әле «Яшь ленинчы» гәзитләре редакцияләре тирәсендә чуалып йөрибез. Менә бермәл үзенең эш бүлмәсеннән кабаланып Зөлфәт абый чыкты да, редактор бүлмәсенә таба атлады. Шулчак ул безне күреп алды.

— Ә-ә, сез мондамыни әле, әй? — диде ул, тукталып. — Хәзер укырга шигырьләрегез бармы?

Җавапны көтеп тә тормастан, баш редактор бүлмәсе ишеген ачты да, безнең икебезне дә эчкә этәрде.

— Менә... яшь шагыйрьләр алып кердем әле, — диде ул һәммәсе дә кыска буйлы, кысык кара күзле кунаклар белән әңгәмә корып утырган Роза ханым Туфитуловага. — Кунакларга үзләренең берәр шигырен укырлар...

Кунаклар дигәнебез монголлар булып чыкты. Татарча бер кәлимә дә сүз белмиләр икән үзләре. Әмма да ләкин урысча чамалыйлар. Алар, елмаешып, безне тыңларга әзерләнделәр.

Зөлфәт абый таныштыра:

— Өметле яшь шагыйрь, күрше Чуашиядән килгән егет Ркаил Зәйдуллин!..

Ркаил әсәрләнеп шигырь укырга керешә. Әлбәттә, татарча...

*Юллардагы тояк эзе сыман*
*Сибелгәннәр икән татарлар...*

Ркаил шигырьнең дүрт юлын укыган саен Зөлфәт абый аны урысчага тәрҗемә кыла. Болай да елмаеп кына тыңлап торган монгол дусларның йөзләренә елмаю отыры җәелә: аңлап тыңлыйлармы шигырьне, әллә аңлаган кыяфәт кенә ясыйлармы, — белмәссең.

— Шулай ук өметле яшь шагыйрь, күрше Башкортстаннан килгән егет Ләис Зөлкарнәев!

Мин, ялгыш ишетмәдемме дип, Зөлфәт абыйга карыйм. Сәерсенгән күзләрем аңа аңлатырга азаплана: «Мин бит Ләис түгел! Ленарис Леронов мин!»

— Укы, әйдә, Ләис. Кунакларны көттермә!

Кунакларның миңа төбәлгән бердәм карашлары астында Зөлфәт абыйга пышылдыйм:

— Мин бит Ләис түгел, мин — Ленарис... Леронов мин!


Ниһаять, Зөлфәт абый төшенде. Әле кунакларга балкып елмаеп, әле миңа елмайгандай итеп:

— Барыбер инде хәзер... Укы! — диде.

Баксаң, бусы баласы гына икән. Кем әйтмешли, алда иде әле анасы...

Хиссез-коры сүзләрне дыңгычлап тутырган шаблон рифмалы бер шигыремне (үзем белән әйбәтрәге юк иде) Ләис Зөлкарнәев булып укый башладым (Мондый шигырь дә язып була икәнлеге Ләиснең ике ятып бер төшенә дә кермәгәндер)...

Үзем укыйм, үзем Зөлфәт абыйга күз кырые белән




# Профессор Тузмөхәммәднең соңгы дәресе

Рәис Габделхак улы Тузмөхәммәд 1926 елны Семипалатински шәһәрендә туа. 1950 елны Мәскәү дәүләтара мөнәсәбәтләр институтын тәмамлый һәм шунда укыта башлый. 1954 елны — кандидатлык диссертациясен, 1979 елны — докторлык диссертациясен яклый, 1982 елдан — профессор. Тагын СССР тышкы эшләр министрлыгының Дипломатлар мәктәбендә, СССР тышкы сәүдә министрлыгы Академиясендә укыта, Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университетында (1979—1981) һәм Кабулдагы иҗтимагый фәннәр институтында (1981—1983) дәүләтара хокук кафедрасы мөдире була. 1984 елдан алып вафатынача ул — Рәсәй Фәннәр Академиясенең Дәүләт һәм хокук институтының җитәкләүче фәнни хезмәткәре.

Р.Тузмөхәммәд — Халыклар хокукларының гомум декларациясе авторы. 1990 елда ул «Юристларның Азия — Тын океан төбәгендәге хезмәттәшлеге өчен» Ассоциациясен оештыра һәм аның президенты була.

...Рәис Тузмөхәммәд белән Казан урамыннан барабыз. Моңарчы бүлмә эчендә генә аралаша идек. Мин алтмышлар тирәсендә дип уйлап йөргән абзабыз урамда күп яшьрәк күренде. Аяк атлавы — төгәл, җиңел, сыгылмалы. Чандыр гәүдәсен төз тота. Йөз-чыраеннан, күз карашыннан елгырлык, реакция шәплек чамалана.

— Нинди спорт белән шөгыльләнә идегез? — дип сорадым.

— Мин — боксчы, — диде Рәис ага.

Шул чакта туган тәэсир истә калган: юлда ул-бу булса, абзый бит мине яклый алачак! Бу чакта Рәис абый инде җитмешенче яше белән барган булган.

Җитмеше тулып күп тә үтмәде, Мәскәүдән хәбәр килде: Рәис Тузмөхәммәд вафат! Шул — яман чир...

Рәис аганың яклавына халык кадәр халыклар да мохтаҗ иде.

«Абхазия» дигән гәҗит Р.Тузмөхәммәднең абхаз-грузин низагын хокук ягыннан тәфтишләгән мәкаләсен «Яктылык һәм өмет нуры» дип атап басып чыгарган.

Аның казакъ һәм үзбәк халыкларына да ярдәме тиде.

Чәчән халкын яклап татар матбугатында хисле-дәртле йөзләрчә язма чыкты.Юридик бәяне исә «Идел»дә Рәис Тузмөхәммәд бирде (1995, № 4). Рәсәйнең Чәчәнстандагы гамәлләре җинаять икәнлеген исбатлады ул. Матбугатта язып кына калмады, БМОның генераль сәркәтибе Бутрос Галига хат та җибәрде. Һәм мондый җавап алды: «Чәчән Республикасындагы вәзгыять җитди борчылу тудыра. Син беләсең инде, күрше төбәкләрдә — Дагстанда, Ингушетиядә, Төньяк Осетиядәге качакларга ярдәм итү буенча Берләшкән Милләтләр Оешмасы үз эшен башлады. Берләшкән Милләтләр Оешмасы бу очракта да солых урнашу белән үк иректе һәм гадел сайлаулар оештыруда булышырга әзер». Менә бит ничек! Ә сугышны кем туктатыр, кем солых урнаштырыр?

Урысның шундый мәкале бар: «Закон что дышло, куда повернул, туда и вышло». Кызганыч ки, әле дөньяда да еш кына закон тәртәсен шулай урысча каералар. Чөнки дәүләтчелеккә тиенгән «олуг» халыкларга шулай файдалы. Калган халыкларның исә йә гаделсезлекне фаш итәрлек галимнәре юк, йә алар кызарып-пешеп тәртәне көчлеләр ягына каерышалар.

«Дәүләтара хокук, «дәүләт» битлеге астында халыклар өстеннән хакимлек иткән бюрократик төзелмәләргә хезмәт итүдән туктый барып, халыклар хокукына, халыкара хокукка әверелсен», — профессор Тузмөхәммәд әнә шуның өчен көрәште. Шушы юлда аның 400ләп хезмәте калды. Менә аларның кайберләре. «Милли суверенитет» (монография), «Урта Азия халыкларының үзбилгеләнүе һәм дәүләтара хокук» (монография), «Кеше хокукы һәм халыклар хокукы сүзлеге». 1995 елда Казанда Рәис ага «Халыкларның хокуклары һәм ирекләре» дигән җыентык бастырып чыгарды. Хокук һәм ирекләребезне беркеткән беренче тулы җыентык бу! Нигә БМО, ОБСЕ кебек оешмаларда мыжгып торган белгечләр чыгармаган аны?

Рәис ага татарның тагын бер күренекле зыялысы профессор Әгъдәс Борһанов белән бергә берничә ел элек Россия Федерациясенең милли азчылыклар турындагы закон лаиһәсен *(проект)* эшләгән иде. Эшләделәр, ләкин Дәүләт думасы аша үткәрә алмадылар. Рәсәйгә милли азчылыклар турындагы канун да, ул азчылык милләтләр үзләре дә кирәк түгел шикелле.

Гомеренең соңгы елларында Рәис ага «Идел» журналын үз итте. Бездә аның тагын «Безне кем яклар? Милли азчылыклар һәм дәүләтара хокук» (1995, № 9), «Кем идек, кем булдык яки Шартнамәдә шартны Мәскәү куя» (1995, № 4) дигән үтә мөһим мәкаләләре чыкты. Профессор «Идел»дә дәүләтара хокук дәресләре алып барды. Хокук фәненең шактый катлаулы даирәсе бу. Сәхифәне ачканда, халык аңлармы, кирәксенерме дигән шик тә бар иде. Юкка шикләнгәнбез. Редакциягә «кирәк, туктый күрмәсен» дип язучылар арасында Мәскәү эшмәкәре дә, Лениногорскидан завод слесаре да, авыл пенсионерлары да бар.

Бу санда менә тагын бер дәрес үткәрелә. Соңгы дәрес...

Рәфикъ ЮНЫС

# Ичкерия — бәйсез дәүләт

Кадерле редакция!

Журналыгызда профессор Тузмөхәммәд дәүләтара хокук дәресләре алып бара. Моның өчен аның үзенә дә, мондый сәхифә ачкан редакциягә дә рәхмәтем зур. Шушы дәресләр уңаеннан сорауларым да бар. Вакыт табып, профессор шуларга җавап бирә алмас иде микән?

Шәүкәт Богданов, «УАЗ» акционерлык берләшмәсе эшчесе. Ульяновски шәһәре.

Кадерле Шәүкәт Богдан!

Сорауларыгыз мине сөендерде дә, гаҗәпләндерде дә. Сез, эшче кеше, сәяси вакыйгаларның хокукый хасиятләрен нечкә тоемлыйсыз. Моңа бик тә күңелем булды. Бу хәл «гади халык»ның сәяси һәм юридик яктан кемнәрдер уйлаганга караганда әзерлеклерәк булуы турында сөйли (Дәүләт думасы депутатларының уртача кимәле белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык сизелә). «Идел» журналының укучылар «географиясе» Татарстаннан күпкә киңрәк булуын белү дә бик күңелле.

Ә хәзер, әйдәгез, Сезнең сорауларга күчик.

*— Күп кенә дәүләтара экспертлар, шулай ук журналистлар да, Рәсәйнең соңгы Конституциясе хәрам кертеп (бюллетеньнәр алыштырылып) кабул ителгәнлеген таныдылар. Аннары бит Конституцияне кабул итү референдумында Чәчән Республикасы белән Татарстан катнашмадылар да. Дәүләтара хокук бу хәлгә ничек карый икән?*

— Әлеге сорауның дәүләтара хокукка мөнәсәбәте юк диярлек. Ләкин юрист буларак мин аңа җавап бирергә тиешмен. Россия Федерациясенең хәзерге Конституциясе үткән конституцияләр белән чагыштырганда, һичшиксез, күпкә өстенрәк. Әмма аны кабул иткәндә һәм Конституция инде гамәлдә чакта хокук бозулар булды һәм була тора. Әйе, Чәчәнстанда референдум бөтенләй узмады, ә Татарстанда ул уңай нәтиҗә бирмәде. Гомумән алганда, 89 субъектның 37 се теге яки бу рәвешле (аяклары яки тавышлары белән) референдум соравына тискәре җавап бирделәр. Юридик яктан караганда ни диган сүз бу? Әгәр дә, Конституциянең үзендә үк күрсәтелгәнчә, аның бөтен субъектлары да тигез хокуклы икән, субъектларның бер өлешенең ихтыяры бүтәннәренә көчләп тагыла алмый, ә бәлки субъектның үз теләге белән генә кабул ителә ала. Теләк дигәнең дә әле субъект җитәкчеләренең теләге түгел, ә бәлки төп суверен булган халыкның сайлаучылар аша ирештерелгән теләге. Ләкин әгәр чынлыкта шулай килеп чыккан икән, ихтыяр көчләп тагылган икән, бездә, димәк, федерация юк, һаман да әле унитар дәүләт. Үзәк сайлау комиссиясе, Рәсәй сайлаучыларының 50 проценттан артыгы хуплап тавыш биргәч бу нәтиҗә каршы тавыш биргән субъектларга да кагыла, дип карар итте. Үзәк мондый субъектларның кайберләре белән шартнамәләр төзеп, РФ Конституциясен бу шартнамәләрнең чыганагы итеп күрсәткәч, хокукый мәгънәсезлек тагын да арта төште.

*— Чәчән республикасы (Ичкерия) һәм Татарстан 1990 елда Бәйсезлек турында декларация кабул иттеләр. Бу чакта әле СССР Конституциясе гамәлдә иде. Анда исә һәр халык, аерылып чыгуны да кертеп, үзбилгеләнү хокукына ия, дип әйтелгән иде. Дәүләтара хокук нигә менә шуны танымыйча, Рәсәй хакимиятенең Ичкерия һәм Татарстан халыкларының язмышын үзе теләгәнчә хәл итү хокукын гына таный? Дәүләтара хокук көч хокукын гына санга сугамыни?*

— Дәүләтара хокукның төп принципларыннан берсе — дәүләтара мөнәсәбәтләрдә көч куллану яки көч куллану белән янаудан баш тарту. «Көч» дигәндә дә әле хәрби, кораллы көч кенә күздә тотылмый. Юридик яктан монысы белән тигез икенче бер принцип бар: халыкларның тигез хокуклылыгы һәм үзбилгеләнү хокукы. Әлеге принцип суверен һәм бәйсез дәүләт кору хокукын да эченә ала. Бу — үтәү мәҗбүри булган принциплар. Аларны бозучылар БМО яки дәүләтләрнең төбәкара оешмасы органнары тарафыннан җавапка тартылырга тиеш. Ләкин мондый санкцияләр ихтыяҗы туганда хокук онытыла, дәүләтләрнең сәяси мәнфәгатьләре алга чыга. Чәчәнстан-Ичкерия мәсьәләсендә дә шулай булды. Дөньяның барча мәмләкәтләре дә диярлек Кремльнең, «бу — безнең эчке эш», диган сүзен җөпләргә ашыктылар. Бу хакта мин «Идел» журналында яздым инде (1995 ел, № 4). Өстәп шуны гына әйтим. Мәскәү хакимияте, үз халкы белән сугыш алып барып, уннарча мең кешене юк итеп, шәһәр һәм авылларны җир белән тигезләп,

Галимнең новаторлыгы шуннан гыйбарәт иде: ул дәүләтара хокукта гүяки «Шәрекъ юнәлешен» ачты. Аның беренче хезмәте Рәсәй белән Иран арасындагы 1921 елгы шартнамәне тикшерүгә багышланды. Шуннан соң ул яңа милли дәүләтләр оешуның хокук мәсьәләләрен, яңа милләтләрнең үзбилгеләнү, аларның миллидәүләт суверенитеты мөгаммәсен *(проблемасын)* ныгытып тикшерә башлады...

Татарстанда референдум үткәрүнең законлы булу-булмавы РФның Конституция судында тикшерелгәндә юридик фәннәр докторы, профессор Р.Тузмөхәммәд Татарстан Республикасының суверенитетын яклап чыкты, аның бу кыю гамәле халкыбыз тарихында беркайчан да җуелмас дип уйлыйм.

Габделхак ӘХТӘМҖАН,
Мәскәү дәүләтара мөнәсәбәтләр институты профессоры.

Дәүләтара хокук
Профессор Туземөхәммәд дәресләре

# Халыкларның тигез хокуклылыгы һәм үзбилгеләнү хокукы

меңнәрчә солдат һәм офицерын үлемгә дучар итеп үз Конституциясенә дә, күптөрле дәүләтара конвенцияләр буенча алган йөкләмәләренә дә төкерде. Менә ул конвенцияләр: Сәяси һәм гражданлык хокуклары турындагы дәүләтара пакт (1966), Икътисади, җәмгыяви һәм мәдәни хокуклар турындагы дәүләтара пакт (1966); Женева конвенцияләренә дәүләтара төстә булмаган низагларга кагылышлы өстәмә II беркетмә; Геноцид җинаятен булдырмау һәм бу җинаять өчен җәзага тарту турында конвенция (1948) һ.б.

*— Дәүләтара хокук нигә чәчән халкының бәйсезлеккә хакын танымый? Рәсәй дә кул куйган дәүләтара документларда, нинди дә булса халыкка (этноска) карата геноцид үткәрелсә, бу халык бәйсез дәүләт корырга хокуклы, дигән маддә бар ләбаса.*

— Дәүләтара хокук буенча Чәчәнстан-Ичкерия — бәйсез дәүләт. Дәүләтара хокукта бәйсезлек кемнеңдер тануына мохтаҗ түгел. Әгәр дә әлеге биләмә-урында вәзгыятьне контрольдә тотучы хакимият һәм бу хакимиятне танучы илат *(население)* бар икән, шактый вакыт эшләп килгән (бу очракта — Рәсәйнең эчке эшләр министрлыгы көчләре һәм хәтта армиясенең дә җәза гамәлләренә карамастан), үз вазифасын үтәгән икән, шул бик җитә.

*— Дәүләтара хокук физик геноцидны гына таный булса кирәк. Ә менә рухи геноцид турында ул ни әйтә? Әгәр дәшми икән, дәүләтара хокукта бу хакта берни дә юк икән, аңа өстәмә кертеп булмыймы?*

— Сез мәсьәләне бик дөрес куясыз. Гәрчә 1948 елгы конвенция этносны, расаны физик юк итүне күздә тотса да, этносны юк итүнең башка юллары да булуын танырга кирәк. Әлеге конвенцияне тулыландыру турындагы тәкъдимегез дөрес. Мин моны башта матбугатта (бәлкем, «Идел»дә үк тәдер) эшләп карап, соңыннан БМО хөкеменә чыгарырга ниятлим.

Ни аяныч, Рәис аганың «Идел»гә язган соңгы җөмләсе бу.

Дәүләтара хокукның (ДХ) нигез ташлары булган 7 төп принципның берсе бу. Яңа принцип: ул беренче мәртәбә 1945 елда — БМО Уставында беркетелә. Башка принциплардан аермалы буларак, аның субъекты дәүләт түгел, халык.

1950-1960 елларда колонияләрнең бәйсезлек алу барышы бик шаушулы булды. Элекке СССР һәм Югославия территорияләрендәге милләтара низагларның исә әле хәзер дә тынып җиткәне юк. Дәүләтара хокук (ДХ) буенча әдәбиятта «бу — декларатив принцип кына, юридик яктан мәҗбүри түгел, «ныклы» хокук нормасы булып тормый дигән, сугыштан соңгы беренче елларда урнашкан ялгыш фикернең әледән-әле тәкърарланып торуы — әнә шуның шаукымы. Ә бит бу принципның ким дигәндә ике «ныклы» чыганагы бар, өстәвенә, алар универсаль чыганаклар да әле: БМО Уставының 1 нче маддәсенең 2 нче пункты һәм Кеше хокуклары турында 1966 елгы һәр ике пактның 1 нче маддәләре. Бу чыганаклар, СССРның хокук варислары буларак, Берләшкән Дәүләтләр Бердәмлегендә катнашучыларның һәркайсы өчен дә мәҗбүри.

Әлеге чыганаклар буенча үзбилгеләнү хокукына «бөтен халыклар да» ия, ягъни теләсә кайсы халык аның субъекты булып тора. Хокукның эчтәлеге (объекты) теге яки бу халыкның үз сәяси мәкамен *(статус)* үзе билгеләү һәм үз икътисади, җәмгыяви *(социаль)* һәм мәдәни үсешен үзе тәэмин итүдән гыйбарәт. Үзбилгеләнү хокукы а) барлык дәүләтләрнең дә «бу хокукны хуплау һәм ихтирам итү вазифасы»; б) халыкның үзбилгеләнүен яклау һәм саклау хокукы белән кәфилләнә *(гарантияләнә).*

Принципның төп гонсырларын *(элементлар)* күздән кичерик. «Тигез хокуклылык» барлык халыкларның да юридик тигезлеген, суверенлыкта нинди дә булса хасиятләрдән бәйсез рәвештә тигезлеген аңлата. Ул, хосусән, һәрбер халыкның барча башка халыкларның хокукларын ихтирам итүен күздә тота — үзбилгеләнү хокукын да кертеп.

Принципның объекты (моның хакында ялгышу-буталулар күп була) иң әүвәл — халыкның үсеше ул. Төгәлрәге, ирекле үсеш. Сәяси мәкам *(статус)* мәсьәләсе шундый үсешнең кәфиле *(гарантиясе)* буларак кына килеп чыга, ул кемнәрдер үсешкә комачаулаганда кискенләшә. Мондый очракларда тышкы көчләргә дә, эчке даирәләргә дә үзбилгеләнүне бары сәяси якка, бәйсезлеккә генә кайтарып калдыру отышлы. ДХ принциплары турындагы декларациядә дәүләтләр сәяси мәкам дигәндә менә шушыны күздә тотарга килешкәннәр: «Суверен һәм бәйсез дәүләт кору; бәйсез дәүләткә кушылу яки аның белән берләшү; бүтән төрле теләсә нинди сәяси мәкам урнаштыру». ДХның таләбе шул: халык үзенең мәкамен ирекле рәвештә билгели алсын. Моның тәңгәл ысулы дип бөтен халыкны сораштыру (плебисцит) яки бөтен халыкның тавыш бирүе *(референдум)* табылган.

Принципның кәфиле *(гарантия)* шуннан гыйбарәт: һәрбер дәүләтнең вазифасы булган «бу хокукны хуплау һәм ихтирам итү», кәгазьдә генә калмыйча, дәүләтләрнең эчке кануннарында, башкарма һәм хокук саклау эшчәнлегендә дә гәүдәләнеш табарга тиеш. Бу хокукны үз эчендә санга сукмаган дәүләт халыкның язмышы турындагы мәсьәләне дәүләтара мәсьәләгә әйләндерә. Икенче кәфил — халыкның, хокукка ярашлы барча ысуллар, шул җөмләдән, кораллыларын да кертеп, үзбилгеләнү хокукын яклау, шулай ук башка дәүләтләр һәм оешмалардан ярдәм сорау һәм алу хокукы.

Башка хокуклар кебек үк, үзбилгеләнү хокукы да мотлакый *(абсолют)* түгел. Бердән, аны гамәлгә ашыру икенче бер халыкның шундый ук хокукын чикләмәсен. Икенчедән, һәр тәгаен очракта аны ДХның калган 6 төп принцибы контекстында карарга кирәк.

ХӘЙДӘР

# Ике хикәя

*Рәфис һәм Нәфис Кашаповларга багышлыйм...*

Бүре Чокыры...

Тау урманының иң аулак урыны халыкта Бүре чокыры дип йөртелә. Бу — кешеләр өчен караңгы, шомлы, чит-ят дөнья. Аралап керә алмаслык чытырман каплаган чокырны зур дөнья белән бары тик бер генә сукмак тоташтыра — бүре сукмагы. Аңа якын баруны адәм баласы әҗәлен эзләүгә тиң күрә... Кышкы айлы төннәрдә шул тарафтан бүре улавын ишеткән кешенең йөрәге убылып китә: бүре азыгы булудан Ходай сакласын!.. Кышкы урман аша туры юлдан үтүченең күзенә бүре эзе чалынса, дога укый-укый теле суелып бетә... И Ходаем, үзең сакла... Әнә бит, кыш айларында югалган кешеләрнең канга батып, өзгәләнеп беткән кием-салымнары яз җитеп көннәр җылынгач кына кар астыннан килеп чыга. Шул ерткыч бүреләр эшедер... Җәй көннәрендә алар болай ук вәхшиләрчә кыланмыйлар да соң...

Урман аша туры юлдан кайтучыларга бүре очрап та исән калучылар бар. Ходай аралап калганмы аларны үлемнән? Ни өчен аңа бүре ташланмаган, ни өчен басу капкасына кадәр озата кайткан? Моны инде беркем дә белми... Әмма шунысы хак: аларның чәчләре чаларып, көмеш төсенә керә, урман белән авыл арасындагы юлда Ходай биргән гомерләренең күп өлешен алар инде яшәп бетергән булалар.

Бүреләр исә, гадәтләренә хилафлык китермичә, һаман да элеккечә яшиләр.

Нишлисең, адәм баласы дөнья яратылганнан бирле бүреләрне кан дошманы исәпли.

Дошман дип ялгышалармы әллә?

Кешеләргә зыян-заурәт сала икән, бүре кавеменең аларны дошман күрүеннән түгелдер бу. Бүрене кешеләр янына ачлык куалап китерә, бүрене ачлык куалап йөртә...

Өер башы Азау адәми затларны дошман итми, аларга тиктомалдан ташланмый, шулай да, алар еректан күренүгә үк, утлы күзләрен кара кан баса, азау тешләре таш чәйнәгәндәге кебек шыкырдый башлый. Кешеләргә бәйле хатирәләре аны чыгырыннан чы-

## АЗАУ




Н. Хаҗиахмәт рәсемнәре

гара... Хәер, адәм балалары да бүреләргә сәбәпсез зыян китерми — Бүре чокырының күптәнге хуҗасы моны белә. Һәрхәлдә, кайчандыр сынган кабыргалары, тишелгән башы өчен кешеләргә барыбер үч сакламый. Яралары төзәлер кебек, тик менә кара бураннарда, көзге явымнарда шул сынган кабыргалары, тишек башы сызлап йөдәтә, йокысын качыра, тәне буйлап пычак сызгандай сызлау үтеп киткәндә, Азау сыкрапыңгырашып куя, тешләрен шыкырдатып ала...

Соңгы тапкыр башына чукмар төшкән буранлы төнне Азау әле дә булса ачык хәтерли, кешеләр камалышыннан качып котылуына һаман да ышанып бетми.

Ай-йолдызларны сүндереп, кош-корт, җәнлек-җанварларны качырып дуамал җил аза купкан төн иде ул. Менә-менә өскә ишелеп төшәм дип, котыра-котыра урман шаулый. Урман шауламый, гүя шулай терек дөньяны йотам дип ачлык шашынып йөри, агач араларыннан зәмһәрир салкын җил булып һөҗүм итә...

Ул төнне җил авылга Бүре чокыры ягыннан — төньяктан исә иде, шуңа күрә авылга туры барып керергә ярамавын башка бүреләр дә сизенә. Эт дигән сатлык кавемнең борыны бүре исен тиз эләктереп ала, җил уңаена авылга барып керсәң, этләр елашып барча халыкны күтәрәчәк. Югыйсә алар бүреләрнең туганы исәпләнә...

Азау, авылны ерактан ук уратып, бүре өерен җилгә каршы алып чыкты. Төнгә күк йөзен томалап актарылаактарыла кара болытлар агыла. Мондый караңгы төннәрдә адәм баласы берничә адым алда ни барын шәйләми башлый. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн ау өчен иң кулай вакыт. Авылда берән-сәрән калтырап янган утлар да сүнә бара.

Соңгы ут сүнеп, авылны мәңгелек караңгы төреп алганда, күзне кисеп уылдаган ачы җилдән бүре өере зират коймасына качып-ышыкланып тора иде инде. Угры җил морҗалардан, бүрәнә ярыкларыннан, абзар тишек-тошыкларыннан әллә нинди исләрне йолкып ала да, кар каплаган япан кырга тарата... Пешкән ит исе, тагын әллә нинди исләр кушылган агымнан Азау үзе өчен иң ягымлы исне аралап ала — яшь бәрән исен сизеп, йөрәге күкрәк читлегеннән атылып чыгардай булып тибә... Сарык бәтиенең исе сөт исе, тирес исе белән катнашып килә дә, зират коймасы тирәсендәге уйдыклы көрт янында тугланып ала... Азауның йөрәк тибеше ешая, анда-санда өргән этләрнең тавышы да ишетелмәс була.

...Беренче булып Азау кузгалды, аңа башкалар да иярде. Азау бәти исе аңкыган агымны югалтмаска тырышты. Ындыр киртәсен сикереп үттеләр... Жуылдап искән ачы җил бүреләр эзен кар бөртекләре белән тигезләп уза. Борынын алга сузып, кар өстеннән Азау шуыша, аның артыннан бер калкып, бер югалып утлы күзләр тәгәри. Бу хикмәткә юлыккан кешенең йөрәге ярылыр иде... Әнә, сарык бәтие шул абзарда булырга тиеш. Азау кар өстенә сузылып ятты, эт өргән авазларга колагын шомрайтты. Юк, этләр әлегә бүре көтүе килгәнен чамаламый, андый-мондый хәл була калса, бер-беребезгә хәбәр итешик дип, болай гына сагаюлары... Бүре килгәнен сизенсә, эт ул тимер чылбырын чәйни-чәйни елый! Җанын кая куярга белми ул сатлык җан! Азауга болар барысы да таныш...

Бүре өере мыштым гына шуыша-шуыша каралтыкураларга якынлашты. Аһ, каһәр... Сарык бәтие буралап җиткергән менә бу сарайда икән... Азау, селәгәен агызып, тешләрен шыкырдатып куйды: каян керергә? Башын күтәреп, көчен чамалап алды да, бер ыргылуда түбәгә сикереп менде, каты-үткен тырнаклары белән түбә саламын пыран-заран китереп ташлады. Калган бүреләр, төрлесе-төрле якка сибелешеп, мал-туар сараен урап алдылар. Кан исен сизеп, кыргый шатлыктан аларның күзләре ут янды...

Түбәгә түшәлгән саламны аралап, үзе сыярлык тишек ясагач, Азау ачы тирес исе аңкыган каралтының нәкъ уртасына сикереп төште. Аңгыра сарыклар каралты почмагына сеңде. Күз ачып йомган арада Азау берничә сарыкны буып ташлаган иде инде...

Шунда әллә нәрсә генә булды. Кайдадыр якында буыла-буыла ачыргаланып эт елый башлады, аңа башка этләр дә кушылды. Азау бермәлгә өнсез калды — шыгырдап капкалар ачылуын, ишекләр шапылдавын, адәм балаларының «Бүре!» дип, дөнья бетереп акыруларын тыңлап торды. Аннары буып ташлаган бәрәннең бугазыннан кабып сыртына ыргытты да, чыгар урын эзләп анда бәрелде, монда сугылды — чыгар тишек тапмады. Ике аяклы затларның кычкырышкан авазлары торган саен якыная...

Берзаман ишек ачылып китте, фонарь яктысын күреп, Азау капкынга эләккәнен аңлады, гаргарә кылган сарык бәтиен ташлап, һөҗүмгә әзерләнде. Тик урыныннан да кымшанырга өлгерә алмый калды — докылдап башына тимер чукмар килеп төште. Азау упкынга очкандай булды, әмма исән калырга теләү үҗәтлеге бүрене тагын айнытты. Бу юлы тимер чукмар сыртына кунды, эчтә нидер чыртлады... Азау кабыргалары сынганын белештерер хәлдә түгел иде — кешеләр зынҗырын өзеп, ничек тә булса качарга ашкына иде. Адәмнәрнең берсе ачы итеп кычкырып җибәрде:

— Азау бит бу!

Әнә шул куркынып кычкырган тавыш бүрегә ниндидер көч бирде, беткән баш беткән дип, бөтен егәрен җыеп, бүреләр затының котын очыручы утка атылды. Фонарь читкә тәгәрәде, бу хәлгә сәерсенеп, кешеләр дә бермәлгә чарасыз калды бугай...

Зынҗырны өзеп, Азау ireккә ыргылды.

— Башына кундыр! — дип акырды кемдер.

Әмма соң иде инде, Азау койманы сикереп үтте дә, офыкка таба очты, актарылып аккан болытлар арасына кереп югалды...

Ул төнне Азау Бүре чокырында төне буе улады, урман ешлыгына яктылык җәелә башлагач кына туктады. Исән котылу шатлыгыннан улыймы, әллә инде авыртуга түзә алмыйча ачудан елыймы ул?..

Якын-тирә авылларда Азауны белмәгән кеше юк, күреп белмәсәләр дә ишетеп беләләр. Көтүчеләрнең кан калтырап торган бүреләре шул — Азау инде. Язгы



айларда көтүгә ул килеп чыкса, бер сарыкны бумыйча китми. Хәйлә-мәкергә аннан да остасын таба алмыйсың, тәнендәге көч-куәте, азау тешләре бөтен малтуарны буып ташларга җитә. Аның шәфкатьсезлеген истә тотып, көтүчеләр бүрегә нәкъ шундый кушамат тактылар да бугай.

Хәзер Азау картайды, тәнендә аккан бүре канында кайнарлык кимегәннән-кими бара. Яшь бүреләр аның бетәшкәнен күрә, тик Бүре чокырына баш булырга берсе дә базмый, тешләре арасында чыкырдап торган усаллыгыннан, күзләрендә телгәләнгән яшеннән куркалар...

Яшь бүреләр азынып китсә, Азау бер генә акаеп карый: барысы да үз эзенә төшә...

Юк, бирешергә ашыкмый әле Азау, теләсә, тәртә юанлыгы агачны да төбеннән чәйнәп өзә ала әле ул!..

Азау, өннән читкәрәк китеп, җылы нурларын мул сипкән март кояшына сыртын куйды да, түше белән ак кар өстенә сузылып ятты. Калган бүреләр дә, кузгалышып, аны арттан, ян-яктан уратып алдылар, тик берсе дә юлбашчы хәрәкәтләрен кабатларга, аның кебек сузылып ятарга җөрьәт итмәде, арт тәпиләренә чүмәшкән хәлдә, Азау нишләр икән дип көттеләр.

Көннәр әлегә суык торса да, кояш нурларының алмаздай кар бөртекләрендәге уен-тантанасы Бүре чокырына да шау-шулы яз киләчәген хәбәр итә иде. Тау битләрен уратып алган урман ешлыгыннан аратирә нинди дер кошлар аваз салгалый, тиктормас тукраннар тырылдап ала. Урманда җан барлыгын сизеп, Азау әнә шул терек тавышларны тыңлап кинәнә, картаеп барган тәнендә сулыгып-сулыгып аккан канын кыздыра иде. Терек тавышлар аңа кояш нурлары кебек үк җылы-ягымлы тоела. Урман ешлыгына караштырып, күзләрен елтыратып куя, борынын алга сузып, нинди дер исне аралап алырга чамалый.

Кояш баер чак җиткән иде инде.

Азау аякларына басты, тешләрен шыкырдатты, аны ураган бүреләр дә, урын алыштырып, арлы-бирле йөренергә кереште.

Быел бүреләр авылга сирәк бара, авыл өстендә аңкып торган мәет исе, урамдагы җансызлык аларның гайрәтен чигерә.

Узган җәй афәт килде. Кар сулары китеп тә өлгермәде, шылтырап җир кипте, югарыдан тамчы да яңгыр төшмәде. Юлларга кызган дары кебек коры тузан ятты. Кояшның мәрхәмәтсез кыздыруына түзә алмыйча иген басулары яргаланды, тишелеп чыккан иген, үлән кара көйде, агач яфраклары җәй башында ук бөрешеп саргайды, елга-инешләрдә су кимеде, күлләрдә су бетеп, төбендәге ләм чатнаган ташка әверелде... Чемченергә дә сутлы үлән таба алмаган мал-туар тузан болыты күтәреп басудан басуга, болыннан болынга күчте, аптырагач, урман эченә таралды. Яндырган кояш астында халык Ходайга ялвара-ялвара әлсерәп алабута җыйды, яфрак җыйды...

Ач үлем җиһан өстенә утлы канатын җәя иде.

Көз җитүгә, юлларда кешеләр күбәя башлады. Авыл халкы, афәтнең иң зурысы кыш айларында булачагын

сизенеп, йорт-җирләрен ташлап каядыр еракка кача...

Кышка кергәндә авыл бушап калды, урамнарда тере мәетләр кебек хәлсез шәүләләр генә күренгәли иде. Ачлык дигән афәт әүвәл кешене акыл-зиһененнән мәхрүм итә. Вәхшигә әверелгән адәм баласы ни кылганын абайлый алмый, күзенә ак-кара күренми, ачлыктан шашынган кешеләр хәтта бер-берләрен тотып ашый башлыйлар...

Кичләрен бүреләр авыл тирәсеннән дә узгалый. Үер башы Азау авыл тарафыннан искән җилгә сизгер борынын куя — морҗаларыннан төтен чыкмый башлаган йортлар ягыннан җил ниндидер сасы ис өертеп алып килә. Мәет исе... Сыер мөгрәгәне дә, сарыклар кычкыруы да ишетелми, кешеләргә тугрылыклы хезмәт итүче этләр дә аваз салмый... Этләр дә кырылып беткәнме әллә?..

Бервакыт төнлә аудан кайтып киләләр иде, Азау бүреләр өерен авылга алып кереп китте. Келәтләрдән, амбарлардан аңкыган мәет исе укшытса да, Ачкүзнең кызыксынуы җиңде — ни булган бу авыл халкына, нигә тәрәзәләрдә утлар янмый, нигә морҗалардан тәмлетатлы исләр таратып төтен күтәрелми? Этләр кая олаккан — нигә өрми алар? Нигә кешеләр кистәнчукмарларын күтәреп, һай-һулап бүреләрне куа чыкмыйлар?

Азау мәчет каршында туктап калды.

Очына ярым ай беркетелгән манарадан элек моңлы итеп азан әйтәләр иде. Кичкырын кешеләрне гыйбадәткә чакырып авыл өстендә яңгыраган шул моңлы азан тавышын тыңларга ялгызы гына басу капкасы төбенә килеп утыра торган иде.

Быел менә кара көздән бирле авыл ягыннан азан тавышы ишетелми, мәчетнең дә ишеге шар ачык икән... Капка төбен кар көрте күмеп киткән... Әнә шул манарага менеп азан әйтүче табылса, авылга тагын җан керер кебек... Тәрәзәләрдә тагын утлар кабыныр, морҗалардан төтен күтәрелә башлар сыман...

Кояш баер алдыннан Бүре чокырында Азау әнә шуларны хәтерләп арлы-бирле йөренде. Башка бүреләр Азауның эчендә ниләр кайнаганын сизенмәделәр, якыная башласа, куркынып читкә тайпылдылар. Сәер иде аның бу халәте...

Март кояшы инде офык читендә кызарып баеп килә, аның соңгы нурлары тау эргәсендә үскән имәннәрне кан төсенә мана. Кошлар да чыркылдаудан туктап калды. Вакыт җиткәндер — Азау Бүре чокырын зур дөнья белән тоташтыручы сукмакка таба атлады. Үер дә шыпан-шыпан аңа иярде.

Сукмак Бүре чокырыннан туры тауга алып менә, тау башыннан исә тирә-як аермачык күренеп ята. Баһадир Азау тау өстендә туктап калды. Кар каплаган ялан кыр өстендә кичке эңгер куерып килә. Әнә тереклеге бетеп кабер тынлыгына чумган авыл... Авыл уртасында караеп мәчет калкып тора. Бүре көтүен Азау авылга таба алып китте.

Кар чүленнән озак бардылар. Яшьрәк бүреләр тәгам өмет итәләр иде, җансыз авылга таба борган өчен Азауга яшертен генә үч кайный иде аларның каннарында, тик берсе дә өердән аерылырга базмый, ахыры ни булып бетәр икән дип, акрын гына баралар да баралар...

Басу капкасына җитәрәк, Азауның үткен күзе кыштырдаган җан иясен шәйләп алды. Сатлыкҗан эт бит бу! Ни ризык тапты икән ул үзенә? Азауның якынлашканын эт сизенеп өлгермәде, кеше мәетен ырылдый-ырылдый ботарлап ята иде. Кешеләргә тугрылыклы хезмәт итүче эт менә нишли!.. Азау бер ыргылуда этне буып ташлады. Эт үләксәсе белән кеше мәете янәшә ятып калдылар, Азау бүреләрне мәчеткә таба алып китте.

Мәчет ишеге һаман да шар ачык иде. Азау ялгызы гына кар көртенә бата-чума ачык ишеккә таба йөзде. Башка бүреләр, кая юл тотты бу, ни кирәк аңа бу манаралы йортта, дип аптыраштылар. Үер башы исә мәчеткә кереп югалды. Бераздан аның улаган авазы авыл өстенә таралды.

— У-у-у! У-у-у...

Азау мәчет манарасыннан йолдызлары җемелдәшкән күккә карап җан ачысы белән улый иде. Бу улау авазында кемнедер ярдәмгә чакыру да, фани дөньяга үпкә дә бар иде кебек.

— У-у-у... У-у-у!

Шулвакыт көтелмәгән хәл булды: әле генә баеган кояш көнчыгыш яктан кызарып күтәрелә башлады. Юк, кояш дип бүреләр ялгышкан икән, ай икән бу... Азау исә тулган айга карап улады да улады.

— У-у-у... У-у-у!

Бу улау авазы шомлы да, моңлы да иде...

...Җир-күкне тоташ дер селкеткән гөрелдәү авазыннан сискәнеп, Азау өеннән атылып чыкты: нәрсә бу, әллә дөнья бетәме? Иртәнге кояшның кар бөртекләрендә уйнаган нурлары күзләрне чагылдырып камаштыра. Башка бүреләр дә, ниндидер афәт килгәнен сизенгәндәй, колакларын шомрайтып торалар, әледән-әле Азау ягына карап алалар. Гөрелде әле якыная, әле ерагая... Моның ни хикмәт икәнлеген Бүре чокырында ятып һич тә чамаларлык түгел. Азау Бүре чокырын зур дөнья белән тоташтыручы сукмакка таба чапты, башкалар да аннан калышмады.

Тау башына менгәч, барысы да ачыкланды.

Бүреләрнең баш очыннан гына галәмәт тавыш таратып аэроплан очып үтте. Бүреләрнең котын очырган нәмәрсә күктә очып йөрүче чит ил аэропланы иде.

«Без җибәргән азык-төлек кая китә икән, ни өчен Идел буенда халык ачтан кырыла, барып җитмиме икәнни аларга без җибәргән азык-төлек?» — дип, чит илләрдәге хәйрия җәмгыятьләренең баш ваткан чоры иде бу. Башка чара тапмагач, азык-төлекләрне аэропланнарга төяп, ил чиген узып, аларның Идел буе авылларын барлап йөрүләре иде. Ачлыктан исән калучыларны искәреп алсалар, авыл башына азык-төлек тутырылган әрҗәләр ташлап калдыралар иде.

Авыл өстендә очып йөргән әлеге аэропланның канатларына кызыл хач белән кызыл ярым ай сурәте төшерелгән иде.

Ачлыктан исән калган хәлсез шәүләләр, аэроплан тавышын ишетеп, урамга агыла. Аэроплан исә түбәннәнрәк очып үтте дә, авыл башына әрҗәләр ташлап калдырды. Берсен-берсе таптый-таптый шәүләләр шунда таба йөгерделәр.

Әлеге хәлләрнең шаһиты булган соры йонлы Азау ак төскә кергән иде.

# Җинаять

Гамил сәгатенә карады: ун тулган иде инде. Йокламадылармы икән дип бераз икеләнеп торды да, ишек яңагындагы кыңгырау төймәсенә басты, эчтәге кыштырдауга колак салды. Анда нәрсәләрдер шалтырады — кемдер ишекне ачарга җыена иде бугай. Бәлки әлеге фатир да түгелдер әле бу? Ишекләрнең берсенә дә, ни сәбәпледер, сан сугылмаган иде. «Әй, ялгышкан булсам, гафу үтенермен дә...» — дип үз-үзен тынычландырды. Йозак келтерәде, ишек ачылды, Гамилнең уйларын раслагандай, зифа гәүдәле, яшьчибәр хатын пәйда булды: әлбәттә, бу түгел, мондый яшь кешеләр фатирга кертәме соң инде?! Хәер, белмәссең...

— Миңа Гарифуллиннар фатиры кирәк иде. Шуны сорармын дип кенә шалтыратуым иде... Борчуым өчен гафу үтенәм.

Хатын елмайгандай итте.

— Гарифуллина? Мин булам инде ул. Сез игълан буенчадыр ич? Эчкә үтегез, бусага аша сөйләшү килешеп бетмәс...

Кызык килеп чыкты бит әле бу: калтырау тавышлы бер карчык «Кем син, ни кирәк?» кебек сораулар белән тинтерәтер дип көткән иде, аның каршысында әнә нинди гүзәл хатын! Пәриеңне саташтырырлык... Гамил каушады, эчкә үтәргә дә, үтмәскә дә белмичә, ишек катында таптанып тора башлады. Хатынның исе китмәде: аны күреп ир-егетләрнең телсез калуына күнеккән инде, ахрысы.

— Үтегез, — дип кабатлады хатын. — Әйдәгез, сөйләшик. Кире уйламагансыздыр ич?

Көтелмәгән хәлдән коелып төшкән Гамил эчке халәтен сиздермәскә тырышты, хатынга ияреп фатирга үтте. Алар сүз алышкан арада бер нәни кызый хатынның халат итәгенә килеп ябышкан иде инде, мөлдерәмә моңсу күзләре ятсынып та, кызыксынып та Гамилгә төбәлгән.

— Яле, кызым, абыйга юл бир.

Кызый халат итәген ычкындырмады, Гамилдән күзен алмыйча: «Әти!..» — дип пышылдады. Гамилнең йөрәге убылып киткәндәй булды: кызый аны әтисе белән бутады... «Ире юк микәнни соң бу хатынның? — дигән уй чагылып узды Гамилнең башыннан. — Күрәсең, юктыр, булса, чит-ятларны мәңге дә өенә аяк бастырмас иде...»

Хуҗа хатын аның уйларын бүлде.

— Сез гаилә белән урнашырга телисезме?

— Юк, юк! — диде Гамил ашыга-кабалана. — Ялгызым...

— Фатирыбыз ике генә бүлмәле булгач, ялгыз кешеләрне генә кертермен дигән идем. Бала белән әйтәсе дә юк инде, — дип тезеп китте хатын аклангандай. — Үземнең дә бала булгач, болгавырга китәр дип куркам. Бала-чаганы уйнаудан тыеп булмый бит аны...

Хатын авыр сулап, көлемсерәп куйды, кызын кулына алды.

— Шулай инде, — дип аның белән килешүен белдерде Гамил, үзе кызыйга карады. Курчак кебек җыйнак-пөхтә киендерелгән бу бала әнисенә тарткан иде. Үсеп буйга җиткәч, бәлки әле әнисен дә уздырыр. Ходай бирсен! Аның кулына берәр тәмле әйбер тоттырасы иде дә бит, белмәде шул Гамил мондый фатирга юлыгасын, белмәде шул мондый нарасый белән очрашасын...

«Үз балаңның күңелен күрер урында, хәзер менә кеше баласын иркәләргә кала инде, — дип гасабиланып уйлады Гамил. — Матур гына яшәп яткан чакта харап булдык. Әй, үзем дә ахмак инде...»

— Мине дөрес аңларга тырышыгыз, — диде хатын читкә карап. — Миңа ир кеше дә, хатын-кыз да барыбер, тик ялгыз гына булсын. — Аннары Гамилгә таба борылды. — Теләсәгез, яшәп кала аласыз.

— Бик шатланып! — диде Гамил. Аның шушындый зур шәһәрдә өч көн рәттән фатир эзләп йөрүе иде. Кыш уртасында фатир табуы җиңел эш түгел.

— Алайса, танышыйк, — дип елмайды хатын. — Минем исемем — Минзилә.

— Мин Гамил булам инде... Түләүгә килгәндә, берничә айныкын алдан биреп куярга була.

Кире борып чыгармасын дигәндәй, түләүне шулай ашык-пошык хәл итәргә тырышуына Гамил үзе дә аптырап китте.

— Башта яшәп карагыз әле, түләү качмас, — диде Минзилә. — Сезгә менә бу бүлмә ошармы? — дип, ишегә ачып куелган йокы бүлмәсенә төртеп күрсәтте. — Урын-җир бар, үзегез белән алып киләсе түгел. Без кызым белән залда йоклыйбыз.

«Сез икәү генәмени? Кызыйның әтисе юкмыни?» — дип аздан гына әйтеп ташламады Гамил. Алла сакласын, күңеленә авыр алган булыр иде. Уйларымны сизә күрмәсен дип, хәтта кызыйга карарга оялды... Эш урынында берничә төн рәттән урындык тезеп йоклаудан аның башы түнгән иде. Урындыкта йоклауны йокы дип буламыни соң?!

— Теләсәгез, бүген үк куна калырга була. Әйтәм бит, урын-җир әзер. Ятасыз да йоклыйсыз...

Гамил уңайсызлана иде, әмма ризалашмыйча да хәлең юк, — аксыргак ашап миңгерәүләнгән сарык кебек күпме йөрергә мөмкин.

— Куна калырга да була...
— Алайса, чишенегез.
Әнә шулай тиз килештеләр. Нарасый бала да, бу абыйның әтисе түгеллеген белгәч, авызын ачып иснәштерә башлады, күз кабаклары йокыга тарта иде. Гамил дә йокысызлыктан тәмам йончыган, чыгырдан чыккан, менә хәзер мендәргә башын төртсә, шундук рәхәт дөньяга чумар кебек тоелды. Фатир шулай җиңел хәл ителеп куйдымыни соң әле? Гамилнең хәтта моңа ышанасы да килмәде.
— Юынырга теләсәгез, ванна менә монда. Әйдә, кызым, чәй куеп җибәрик әле, аннары абыйга урын җәярбез, иеме?
— Зинһар өчен чәй куя күрмәгез... Йоклар алдыннан...
— Ихтыярыгыз, — дип килеште Минзилә, кызын күтәреп, йокы бүлмәсенә урын җәяргә кереп китте.
Пальтосын-бүреген салып чөйгә элгәндә, Гамил хуҗа хатынның чиста-пөхтә яшәве турына уйлады. Ванна бүлмәсендә дә һәр нәрсә тәртиптә. Бала тәрбияләгән хатыннарның гадәттә барысын да тәртиптә тотарга өлгерлекләре җитми. Тик менә ни өчен алар икәү генә яши? Ире белән аерылышканмы? Аерылышкан гына булса, яңадан кушылу ихтималын истә тотып, ир затын фатирга кертмәс иде... Хәзерге заманда кияүгә чыкмыйча да бала табалар, анысына да күнегеп киләбез бугай... Ярый соң, барысына да бүген үк ачыклык кертеп булмас, тора-бара һәммәсе дә аңлашылыр.
— Рәхәтләнеп йоклагыз, — диде Минзилә ваннадан чыгып килүче Гамилгә. — Сезне беркем дә борчымас, безнең кайтасы кешебез юк.
— Рәхмәт...
Минзилә кызын күтәреп олы якка кереп китте.
Гамил йокы бүлмәсенә үтте, нишләргә дә, нинди карарга да килергә белмичә бүлмә уртасында озак кына басып торды. Ни булды соң әле, ни өчен ул чит-ят фатирда куна-төнә йөрергә тиеш булып чыкты?
Хатыны белән гауга чыгарган сәбәп гади иде. Бервакыт Гамил авылдан яшь чактагы фотоальбомын алып кайтты. Алып кайтты да китап киштәсенә куйды — альбомның барлыгын да онытты. Шул нәмәрсә низагка сәбәп булыр дип кем белгән?! Сизенгән булса, альбомны авылдан алып та килмәгән булыр иде. Ятсын иде шунда тузан җыеп... Әмма соң иде инде: беркөнне хатыны альбомны карап утырганда кара коелды. Бер фотосурәтне аерып алып, Гамилнең йөрәгенә чәнчеп сорады:
— Кем бу? Менә бу хатын кем? Йә, кемең бу?
— Каян хәтерлим инде мин аны? — диде эшнең нәрсәдә икәнен аңламаган Гамил. — Нигә кирәк ул сиңа?
— Ул миңа кирәкми! — дип, хатыны кабынып китте. — Ул миңа сукыр бер тиенгә дә кирәкми! Ул менә синең сыман бойлыксыз, тотнаксыз мужикларга кирәк мондый урам себеркеләре! Әйтәм ул өстерәлчек миңа гел мыскыллап карый... Менә нигә икән әле!
— Әллә ниләр уйлап табасың син, — дип, Гамил аны сүрелдермәкче иде дә, булмады.
— Синең дә башыңны әйләндердемени бу өстерәлчек?! — дип үкседе хатыны күз яшьләренә буылып. — Белмәгәнгә салышып торган була тагы... Ярар, мине беткәнгә саныйсың икән — сана... Шушы сурәтне түшеңә тәре итеп тагып йөр! Бөтен бәхетең шуннан булсын!
Шуннан китте, китте... Гамил белән кайчандыр сурәткә төшкән кызый (хәзер инде кияүгә чыкмыйча гына ханым булган) аның хатыны белән бер заводта, хәтта бер бүлектә бергә эшли икән. Гамил ул хатынның язмышыннан бөтенләй хәбәрдар түгел, гомумән, кем икәнлеген дә анык хәтерләми иде. Фотосурәткә дә очраклы гына төшелгән — ниндидер туйда, ахрысы... Очраклы төшелгән дип исбатлап кара инде син, нинди хатын ышансын сиңа?!
Низаг көннән-көн көчәя барды, хатын белән ир арасында ниндидер кара пәрдә корып куйды. Хатыны аш пешерүдән, кер юудан туктап калды, улын әтисеннән читләштерде. Башкача түзәр әмәл калмагач, Гамил хатынын, улын ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булды. Бәлки хатыны Гамилнең гаепсез икәнлеген ачыклар... Ул моңа өметләнә иде.
Менә хәзер ят фатирда Гамил беренче төнен кунарга әзерләнә. Күрше бүлмәдә нәни кызы белән чибәр Минзилә... Минзиләне күз алдына китерүгә, Гамилнең йөрәге «жу» итте. Әгәр дә шундый чибәр хатынга фатирга керүен үз хатыны белсә? Бетте баш... Хәер, каян белсен икән ул аны? Шундый зур шәһәрдә Гамил яшәгән фатирны эт белән эзләсәләр дә таба алмаслар иде. Тукта, нигә боларны уйлап баш катыра соң әле?! Алдагысын Алла гына белә.
Гамил үзе яшәячәк бүлмәне күздән кичерде. Бүлмәдә бер карават, язу өстәле, ике урындыктан башка җиһаз юк иде. Язу өстәле караватка янәшә куелган, өстәл өстендә лампа да бар икән. Люстра утын сүндереп, лампаны кабызды, дипломатыннан бүгенге газеталарны чыгарып, өстәлгә ташлады. Чишенеп яткач, кулына газета алды, тик арыган тәнне урынҗирнең йомшак җылылыгы эретте, күзләрен йокы басты, уйлау сәләте кимеде. Ул үрелеп утны сүндерде... Аны рәхәт җиңеллек кочып алды. Тәрәзәдән төшкән ут шәүләләре бөтерелеп каядыр еракка очты, стеналар, йокларга теләгән кешегә иркенлек бирергә теләгәндәй, каядыр артка чигенде. Гамил таралып йокыга китте...
Төендә күргән рәхәтлекләр төштә дә кабатлана диләр — хактыр. Гамил җәй айларында балыкка йөрергә ярата. Шуңа күрә, бөлеп-бетеп булса да, дачаны да Идел буеннан сатып алган иде. Әле дә ул Иделгә балык тотарга бара икән... Күктән җылы кояшның назы-иркәсе бөркелә. Шундый да хозур җәйге көн. Кармак сабына чыбык сындырырга дип, Гамил таллар арасына керде, кесәсеннән пәке чыгарып, бер чыбыкка үрелгән генә иде... Йа Алла, ни булды?! Тал чыбыклары аның тәнен сарып-чорнап та алдылар. Юан бер чыбык аның муены тирәсендә сырпалана башлады, аннары буарга ук керешә. Гамил тал чыбык-

ларыннан котылырга тырышып чапаланды — әмма алар аны җибәрмәде. Ул куркуыннан күзләрен шар ачып сикереп торды, үрелеп утны кабызды. Йөрәге күкрәк читлеген ватардай булып тибә...

Ут яктысында берара утыргач, азрак тынычланды. Әле күргән төше төш түгел, гап-гади саташу иде. «Урын-җир алышынды шул, яңа урынга ияләшкәнче аз-маз саташтырыр инде, — дип, Гамил үз-үзен тынычландырырга тырышты. — Менә күнегеп җитим әле, берни дә булмас...»

Яңа урында йоклый алмау Гамил өчен таныш халәт. Аңа командировкаларда еш булырга туры килә. Ул эшләгән проект институтында командировкага йөрердәй кешеләр бармак белән генә санарлык. Кайсылары өлкән яшьтә, кайсылары авыру, яшь балалы хатын-кызлар күп. Андыйларны ни җаның белән чит шәһәргә, районнарга чыгарып җибәрәсең инде? Шуңа күрә дә Гамил кебекләргә юл йөрергә кала. Командировкаларда нинди генә урыннарда төн кунарга насыйп булмады, төне буе саташып чыккан вакытлары да аз түгел, йоклаганда бастырылу кебек ямьсез нәрсәләр турында сөйләп тә аны шаккатыра алмыйсың. Кандалалы-бетле кунакханәләр дә эләккәли, тараканы турында әйтәсе дә юк. Яңа урынга ияләшкәнче берничә көн йокы чырае күрмисең, башың тубал була, миңгерәүләнеп бетәсең...

Гамил сәгатенә күз салды — төнге унике тулып узган иде инде. Хәзер үк ятып йокламаса, эштә тагын, дарулаган чебен кебек, йокылы-уяулы, аңгы-миңге йөриячәк иде. Бәлки ул бастырылган булгандыр? Гадәттә, чалкан ятканда бастырыласың... Мендәрен уңайлап-йомшартып салгач, яны белән ятты, юрганын башыннан ук бөркәнде. Бераздан йомарланып йокыга китте, тагын төш күрә башлады. Имеш, туган авылына кайтып килеше икән. Әнисе аны каршы алырга капка төбенә үк чыгып баскан. Әнә ул кочагын җәйгән, үзе шундый яшь! Әнисенең мондый ук яшь чагын Гамил белми. Әле узган җәй авылга кайткан чакта, әнисенең җыерчык баскан йөзен, хәлсез гәүдәсен күреп, җаны сыкраган иде. Бу юлы әнә ничек яшәргән ул! Гамилнең күңеле шатлык-куаныч белән тулды. Сөенеченнән: «Әнием!» — дип кычкырырга теләде, тик тавышы чыкмады. Тукта, ни булды соң әле? Әнисе түгел икән ич, түгел шул!.. Нindидер таныш булмаган чибәр хатын бу... Таныш та кебек... Тукта, кайда күргәне бар иде соң бу хатынны? Кайда күрде, кайсы юл чатында, гомеренең нинди борылышында күрде соң әле ул аны? Әмма ничаклы тырышса да, хәтеренә төшерә алмады. Гамил суырылып яшь-чибәр хатын кочагына барып керде. А-а-а! Гомерендә дә мондый рәхәтлекне татыганы юк иде әле аның. Нинди ләззәтле кочак! Гамил чибәр хатын кочагында әреде-бетте. Сабыр ит, нишләде ул? Үз хатыны күрсә, белеп алса, башын ашаячак ич! Гамил бераз гына тартылып куйган иде, чибәр хатынның кулы аның муенына туры килде дә буыла башлады...

— А-а-а!..

Гамил гаргара кылганда уянып китте, тәне ут булган иде. Күз алдыннан нindидер күләгә шуышып узды да стенага сыенып юк булды. Гамилнең йөрәгең шом алды, үрелеп тиз генә утны кабызды. Каршында янә нindидер күләгәләр биешеп узды. Ул күзләрен угалады, игътибар белән бүлмәне күздән кичерде, тик бернинди дә шикләнердәй нәрсә күренмәде. Йокы бүлмәсенең ишеге ябык иде. Әй, ахмак, төштә күргәнне өндә эзли түгелме соң? Үзенең шик-шөбһәләреннән үзе үк каһкаһәләп көләсе килә башлады, әмма көләрлек хәлдә генә түгел иде. Иркенләп, тирән итеп сулыш алгач, тагын караватка сузылып ятты. Рәнҗеп хатынын искә төшерде. Җәй көне мондый хәл килеп чыккан булса, дачада гына кунып йөрер иде... Аларның дачасы Казаннан ерак түгел — кырык минут электричкада барасы. Дача йорты тактадан гына шул, җылытулы түгел. Агачка бәяләр күтәрелгәнче бура сатып алырга өлгермәде... Югыйсә, бурадан җиткерергә киңәш иткәннәр иде дә, акыллы киңәшкә колак сала белмәде. Бурадан җиткерүчеләр хәзер морҗа чыгарып куйдылар, кыш айларында да ял көннәрен бала-чагалары белән дачада гына үткәрәләр.

Тәненә салкын йөгергәч, Гамил янә юрганга төренеп ятты, тик күзенә йокы кермәде. Әле генә күргән төшен хәтерләде: әнисе, чибәр хатын... Минзиләгә охшаган идеме төшендәге чибәр хатын? Алар арасында уртаклыкны күпме генә эзләсә дә таба алмады. Минзиләнең саташуга ни катнашы булсын инде? Башына шундый ахмак уй килүенә үз-үзен битәрләп алды. Саташуын кемгә сылтарга белмичә ятамы? Әй, ахмак... Инде таң беленергә дә күп калмагандыр? Бу төне дә шулай йокысыз үтәрме икәнни? «Әллә тәмәке тартып керим микән?» — дип тә уйлаган иде, әмма уеннан кире кайтты. Әле хуҗа хатынның холкын белмәгән килеш төне буе йөреп чыгу килешмәс. Тынгысыз кеше керткәнмен икән дип, шикләнүе ихтимал... Ичмасам, йокы даруы да юк бит... Гамил түзәргә тырышты, йокыга китәргә теләп, күзләрен йомды, әмма күз алдында яктылык калды. Утны сүндермәгән икән...

Бүлмәне караңгылык басты...

Урамда сукбай этләрнең елавы ишетелә...

Йоклап китәр өчен ул нинди генә сәбәпләр эзләп карамады. Әле уң ягына, әле сул ягына әйләнеп ятты. Гомеренең иң күңелле мизгелләрен хәтеренә төшерде. Гамилләрнең авылыннан ерак та түгел урман эчендә куыш имән бар иде. Әкиятләрдә генә сөйләнә торган куыш имән янына балачагында ул еш бара иде, куышка кереп төн куну турында хыяллана иде. Кереп утырасың, тирә-юньдә куркыныч кыштырдаулар, нindидер төн кошлары шомлы итеп кычкыра... Хыялын тормышка ашыра алмады, әлбәттә. Әмма куышта төн кунуын күз алдына китергән чакларда ул эреп йокыга китә торган иде.

Бу гадәте үскәч тә онытылмады. Гамилгә аның файдасы да тия торган иде: чит-ят җирләрдә кунарга туры килгәндә үзен шул имән куышында дип хис итә. Имеш, куышта бөгәрләнеп ята, үзе дә сизмәстән йоклап та китә.


Менә хәзер дә ул үзен малай итеп күз алдына



Фидаил Әүхәтдин улы Шиһапов
Югары Ослан хакимият башлыгының беренче урынбасары

# Татарстан авыл җирлеге торак-коммуналь хуҗалыгының Югары Ослан районы хакимияте каршындагы күптармаклы производство предприятиесе.







Валентин Андреевич Яковлев
Торак-коммуналь хуҗалыкның күп тармаклы производство предприятиесе директоры

Адрес: Татарстан, Югары Ослан, Автодорожная ур., 4.
Исәп-хисап счеты: N 000508202 в Верхнеуслонском отд. ТСХБ.


## Югары Осландагы чистарту корылмасы






# ТАТСЕЛЬЖИЛКОММУНХОЗ

## производство берләшмәсе



Киндерле котельные, Биектау районы.



Биектаудагы котельный.



Югары Ослан котельные.

Адрес: 420111, Казан,
Дзержинский ур., 10
Тел: 32-50-40
39-73-82

**Җан җылысы, күңел якмысы**

# Казанское коммунальное предприятие
# Производственное объединение
# ГОРЭЛЕКТРОТРАНСПОРТА



Факс 38-24-92 Телефон 32-62-62

420084, Казан шәһәре,
Бауман ур., 66
тел: 32-05-61, 32-50-25



# Татарстан махсус фәнни-реставрация идарәсе



*Журналның 10 нчы санында Татарстан махсус фәнни-реставрация идарәсе директоры Наил Зыя улы Йосыпов белән әңгәмә корган идек («Узган заман киләчәкне уза»). Вәгъдә ителгәнчә, Наил әфәнде бу санда безне Г.Тукай туган, яшәгән урыннар буйлап сәяхәткә чакыра: махсус фәнни-реставрация идарәсе башкарган эшләр белән таныштыра.*

Индекс 73951